# ИСЛАМ ДИНЕ КҮЗЛЕГЕННӘН БӘЛА-КАЗАЛАР ҺӘМ ТОРМЫШ АВЫРЛЫКЛАРЫ

***Рус теленнән тәрҗемә***

***(асылы https://asar-forum.com сайтында)***

Җәмгыятьтә – әгәр дә кеше муллыкта һәм иминлектә яши икән, димәк, Аллаһ Тәгалә бу бәндәсен ярата һәм аңа яхшылык тели, ә инде киресенчә, кеше фәкыйрьлек, чир-хасталык һәм төрле бәла-казалар күреп яши икән, димәк, Аллаһ бу бәндәсе белән риза түгел, аңа яхшылык теләми – дигән фикер киң таралган.

Бу китапчык әлеге ялгыш фикерне төзәтү, дөньялык тормышының чын максатын аңлату һәм авырту-чирләрнең, бәла-казаларның, фәкыйрьлекнең һәм башка борчу-мәшәкатьләрнең бу дөньядагы урынын җиткерү нияте белән төзелде.

## КЕРЕШ СҮЗ.

**БисмиЛләһи-р-Рахмәәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Барча мактау Аллаһ Тәгаләгә тиешле! Без Аңа шөкер кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Нәфсебезнең начарлыгыннан, бозык гамәлләребездән Аллаһ Тәгаләдә сыену эзлибез!

Кемне Аллаһ туры юлга күндерсә, аны беркем дә адаштырмас, ә кемне адаштырса – беркем дә туры юлга күндерә алмас. Шәһадәт бирәмен – Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер иләһ юк, Ул берүзе, тиңдәшсез һәм шәһадәт бирәмен – Мөхәммәд Аллаһның колы һәм илчесе!

Һәм аннан соң:

Әгәр дә кеше, тыштан караганда, иминлектә яши икән, күпчелек кешеләр Аллаһ Тәгалә бу бәндәсен ярата, аңа шул рәвешле Үзенең ризалыгын белдерә дип уйлыйлар. Мондый фикер хәтта Аллаһка гыйбадәт кылучы мөэмин-мөселманнар арасында да таралган. Алар үзләренең гамәл-гыйбадәтләрен, бары тик, Аллаһ Тәгалә аларның бу дөньяларын яхшыртсын, үзләренә һәм балаларына иминлек бирсен, чирләрдән, кайгы-хәсрәтләрдән сакласын, дигән ният белән генә кылалар. Шуңа күрә, Аллаһның әмерләрен үтәүләренә һәм тыйганнарыннан ерак булуларына карамастан, тормышларында төрле бәлаларга, авырту-чирләргә һәм башка борчуларга юлыксалар, алар бик нык аптырашта калалар, хафага төшәләр. Шул ук вакытта, Аллаһтан ерак булып яшәүче күршеләре, туганнары һәм таныш-белешләре бертөрле иминлектә яшәгәнен күрәләр.

Алар намаз, сәдака, ураза, ата-анага хөрмәт, туганлык җепләрен ныгыту, золымлыктан ерак булу һәм башка төрле саваплы гамәлләрне кылганда, Аллаһ Тәгаләнең Кыямәт көненә әзерләнгән әҗере турында уйламыйлар. Үзләренең гамәлләре өчен бу дөньяда ук әҗер көтәләр – Аллаһ Тәгалә аларның мал-мөлкәтләрен сакласын һәм арттырсын, үзләренә һәм гаиләләренә саулык-сәламәтлек, иминлек бирсен һәм башка шундый дөньялык белән бәйлене генә өмет итәләр. Җәһәннәм газабыннан котылу турында да алай борчылмыйлар, чөнки аларны бу дөньядагы авырлыклар, борчу-мәшәкатьләр күбрәк куркыта. Шулай ук, Җәннәткә омтылышлары да түбән, чөнки күбрәк дөнья нигъмәтләре турында кайгырталар.

Чынлыкта, мондый кешеләр бик хәтәр хәлдә, чөнки бу Аллаһ Тәгаләгә тиңдәшлек кылуның (ширек) бер төре. Бу хәл кешеләрнең игътибарыннан шуның хәтле яшеренгән, хәтта имам Мөхәммәд әт-Тәмими үзенең тәүхид (бериләһлек) темасына багышланган китабында бу мәсьәләгә карата аерым бүлек биргән һәм аны

“*Саваплы гамәлләрне дөнья нигъмәтләрен алу нияте белән кылу – ширекнең бер төре*” дип атаган һәм Аллаһның шундый сүзләрен китергән: **“Берәү дөнья тереклеген генә вә дөнья тормышының матурлыгын теләсә, Без аларга дөньяви эшләренең файдасын дөньяда биреп бетерербез һәм аларга дөньяви эшләренә кимчелек китерелмәс. Әмма ахирәттә аларга уттан башка җәза булмас вә дөнья эшләре һәлак булыр, вә гамәлләре батыл булыр”.** (“Һүд” сүрәсе, 15-16 нчы аятьләр).

Аллаһ Тәгалә мондый кешеләргә гамәлләре өчен инде бу дөньяда ук тиешле әҗерен биреп бетерергә вәгъдә биргән, әмма ахирәттә аларга өлеш калмас. Әлбәттә монда, кешегә дөнья матурлыгын һәм байлыгын теләргә ярамый дигән сүз бармый, әмма бу аның төп омтылышы булырга тиеш түгел.

Аллаһ Тәгалә әйткән: **“Кешеләрдән шундый бардыр, ул әйтәдер: “Раббыбыз! Безгә дөньяда теләгәнебезне бир”, – дип. Әмма ахирәттә аңа бернинди дә өлеш калмас. Ләкин кешеләрдән шундый бардыр, ул әйтәдер: “Раббыбыз! Безгә дөньяда да һәм ахирәттә дә яхшылыкны бир һәм безне җәһәннәм утыннан сакла”, – дип. Аларга кәсеб иткән гамәлләре өчен Аллаһтан өлеш булыр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 200-202 нче аятьләр).

Мәшһүр галим шәех Гәбдүррахмән ибн Нәсыр әс-Сәгди бу аятьнең тәфсирендә болай диде: “*Аллаһ Тәгалә бу аятьтә барлык кешеләрнең дә, яхшылыкка өмет итеп һәм зыяннан саклану сорап, Аллаһка дога кылганнарын җиткерде, әмма аларның омтылышлары төрлечә. Кемдер үзенең түбән нәфес теләкләренә буйсынып, бары тик дөнья байлыгын гына сорый. Мондый кешеләр ахирәт нигъмәтләреннән мәхрүм булырлар, чөнки үзләре ахирәттән читләштеләр, барлык теләкләре дөнья малы һәм рәхәтлекләргә ия булу белән генә бәйле иде. Әмма, шул ук вакытта, икенче төр кешеләр дә бар иде – алар бу дөньяның да һәм ахирәтнең дә нигъмәтләренә омтылдылар. Аллаһтан диннәре һәм дөньялары өчен яхшылыкны сорадылар. Ахыр чиктә һәрбер төркем эшләп тапканын һәм лаек булганын алыр*”.

Ә бит, кешенең иманы һәм Аллаһны яратуы арткан саен, аның Аллаһның ризалыгын һәм яратуын алырга омтылуы башка омтылышлардан өстен була башлый.

Аллаһ Тәгалә Көрьәндә әйтә: **“Аллаһ Тәгалә мөэмин ирләргә вә мөэминә хатыннарга асларыннан елгалар агучы җәннәтләр хәзерләде, алар анда мәңге калырлар, вә Гәден җәннәтләрендә яхшы урыннар хәзерләде, вә аларга Аллаһның ризалыгы булыр, Аның ризалыгы һәрнәрсәдән бөегрәк. Бу зур уңышка ирешүдер”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 72-нче аять).

Шәех әс-Сәгди бу аятьнең тәфсирендә әйткән: “*Әлеге сокландыргыч Җәннәт бакчалары – калебләр аларга ашкынырга, ә җаннар аларны теләргә лаеклы, чөнки тәкъва булып изгелек кылучылар мәңгелек Гаден җәннәтләреннән беркайчан да аерылмаслар. Ә Аллаһның ризалыгын алу – барча Җәннәт нигъмәтләреннән өстен*

*булачак. Бу нигъмәтләр Аллаһның тәкъва колларына алай рәхәтлек бирмәсләр иде – әгәр дә аларга Аллаһның Үзен күрергә мөмкинчелек бирелмәсә һәм алар үзләрендә Раббыларының ризалыгын тоймасалар, чөнки Раббыларын яратып, Аңа гыйбадәт кылучыларның төп омтылышлары шулдыр. Шуңа күрә, Аллаһ Тәгалә үзенең колына ризалыгын белдерсә, моннан да күркәмрәк нигъмәт була алмый. Бөек уңышка ирешү – шулдыр, аннан соң гына кеше калган теләкләрен алачак һәм бөтен курыккан күңелсезлекләрдән котылачак, күркәм һәм зиннәтле тормышта яши башлаячак. Йә Раббыбыз Аллаһ, Үзеңнең киң рәхмәтең һәм юмартлыгың белән безләрне тәкъва һәм игелек кылучы колларыңнан кылсаң иде!*”.

Шуны да аңларга кирәк, Аллаһ Тәгаләнең Җәннәт бакчаларында әзерләнгән нигъмәтләренә карата игътибарсыз булу – Раббыларыннан мөстәкыйльлек һәм нигъмәтләреннән бәйсезлек күрсәтергә теләп, Аңа карата хөрмәтсезлек күрсәтү булып тора. Шуның өстенә, алар Җәһәннәм газабыннан куркулары булмауларын да күрсәтәләр, ә бит Аллаһ Үзенең газабы каты булуын җиткерде. Мондый кешеләр үзләренең аскетлыкларында барча чикне узалар һәм аскетизмга бернинди дә катнашы булмаган хәлгә төшәләр. Бит дөньяга һәм аның байлыгына карата аскетлык күрсәтергә кирәк, ахирәт нигъмәтләренә һәм газабына карата түгел.

Чынлап та, кем үзенең бу дөньядагы халәте яхшы булсын дип кенә Аллаһка гыйбадәт кыла, шул ук вакытта, Җәннәт нигъмәтләренә дә, Аллаһның ризалыгына да, газабыннан котылуына да омтылмый икән, мондый кеше Раббысына карата ширек кыла, алдан әйтеп үтелгән аятьтә кебек: **“Кешеләрдән шундый бардыр, ул әйтәдер: “Раббыбыз! Безгә дөньяда теләгәнебезне бир”, – дип. Әмма ахирәттә аңа бернинди дә өлеш калмас”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 200-нче аять).

Шулай ук, моңа пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ [1] хәдисе дәлил булып тора: Гайшә (Аллаһ аннан разый булсын) бервакыт пәйгамбәребездән ﷺ сораган: *“Йә Аллаһ илчесе, Җаһилият*[2] *заманында Гәбдуллаһ ибн Җүдгән туганлык җепләрен кайгырта, фәкыйрь-мескеннәрне ашата һәм башка төрле изгелекләр кыла иде, бу аңа файда китерерме икән?”* Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ моңа җавап итеп: ***“Юк. Ул үз гомерендә бер тапкыр да “Йә Аллаһ, Кыямәт көнендә минем гөнаһларымны кичер” дип әйтмәде”*** – дигән. (Мөслим 214, Әхмәд 24892).

---

[1] “Аллаһның аңа мактавы һәм сәламе булсын” дигән мәгънәдәге сүзләр.

[2] Ислам дине килгәнче вакыт. [Тәрҗемәчедән].

## БУ ДӨНЬЯ НИ ӨЧЕН БАР ИТЕЛГӘН?

Дөньялыкта бара торган барча вакыйгаларны дөрес күзаллау өчен, кешеләр бер нәрсәне яхшы итеп аңларга һәм үзләштерергә тиешләр – бу дөнья ни сәбәпле һәм нинди максат белән бар ителгән икән соң?

Аллаһ Тәгалә безгә моны Көръәндә җиткерә: **“Кеше һәм җенне бары Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым”.** (“Әз-Зәрият” сүрәсе, 56-нчы аять).

Шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Ул үлемне һәм тереклекне бар кылды, сезне кайсыларыгыз гамәлләре белән яхшырак булыр икән дип сынар өчен”.** (“Әл-Мүлк” сүрәсе, 2-нче аять).

Шулай ук Ул әйтә: **“Дөреслектә, Без җир өстендәге барча нәрсәне җиргә зиннәт өчен бар иттек, кешеләрдән кайсыларының гамәлләре яхшырак булыр дип сынар өчен дөньяны төзедек һәм зиннәтләдек. Җир өстендә булган барча нәрсәне җансыз комга әйләндерербез”.** (“Әл-Кәһеф” сүрәсе, 7-8 нче аятьләр).

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Барча кеше үлем ачысын татучыдыр, Без сезне яманлык белән дә, яхшылык белән дә сынарбыз, боларны сезгә фетнә кылып имтихан йөзеннән, соңрак Безгә кайтырсыз”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 35-нче аять).

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Әллә кешеләр “Без иман китердек” дигәннәреннән соң төрле сынаулар белән Аллаһ тарафыннан имтихан ителмәбез дип уйлыйлармы? Болардан элек яшәгән кешеләрне дә сынап карадык. Аллаһ, әлбәттә, дөрес сөйләүчеләрне һәм ялган сөйләүчеләрне ачыклар”.** (“Әл-Гәнкәбүт” сүрәсе, 2-3 нче аятьләр).

Шулай ук Аллаһ әйтте: **“Йә мөэминнәр! Сездән әүвәлге кавемнәргә килгән сынаулар сезгә дә килмичә җәннәткә керербез дип исәплисезме? Аларны ачлык, сырхау, бәлә-казалар һәм сугыш авырлыклары тотты, хәтта көчләре бетте, пәйгамбәр һәм аңа ияргән мөэминнәр “Аллаһның ярдәме безгә кайчан килер икән”, – дип әйтә иделәр. Чынлыкта, Аллаһның ярдәме якындыр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 214-нче аять).

Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Без сезне, әлбәттә, әзрәк куркынычлык һәм ачлык белән, малларыгызны, якыннарыгызны, игеннәрегезне һәм бакча җимешләрегезне киметеп сынарбыз. Аллаһтан сынар өчен бирелгән төрле авырлыкларга сабыр булучыларны сөендер”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 155-нче аять).

Аллаһның әлеге һәм башка сүзләре, шулай ук Аның пәйгамбәренең ﷺ хәдисләре, бу дөнья – яхшылыкка һәм золымлыкка тулы җәза бирү урыны түгел, ә сынау урыны икәнен күрсәтәләр. Бу сынаулар кайгы һәм сөенеч, фәкыйрьлек һәм байлык, сырхау һәм сәламәтлек, бәла-каза һәм иминлек рәвешендә булырга мөмкиннәр.

## БӘЛА-КАЗАЛАРНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ.

Бәла-казалар һәм аларның нәтиҗәләре кеше өчен яхшылык белән дә, яманлык белән дә тәмамланырга мөмкин (Аллаһ теләсә, бу турыда алга таба сөйләрбез), ә бу бүлектә бәла-казаларның сәбәпләре турында сөйләп үтәсе килә. Шуны искә алырга кирәк – бәлалар ике төргә бүленә: гомуми, ягъни барлык кешеләрне һәм җәмгыятьне чолгап алган, һәм хосусый – аерым бер шәхескә генә кагылган.

Гомуми бәла-казаларның сәбәбе булып җәмгыятьтә төрле гөнаһлар таралу тора, хәтта җәмгыятьтә кешеләр арасында тәкъва һәм изге кешеләр очраса да. Килгән бәла – җәза өчен, гөнаһлардан чистарту яки сынау өчен җибәрелгән булырга мөмкин.

Алга таба, кайсы бәла-каза гөнаһлардан чистарту өчен җибәрелгән Аллаһның рәхмәте булуы, ә кайсысы җәза буларак килүе турында сүз барыр.

Әгәр дә җәмгыятьтә яманлык, гаделсезлек, эпидемияләр һәм төрле табигый хәвефләр тарала икән, мондый хәл – кешеләрнең гөнаһлары сәбәпле, аларның үз куллары белән кәсеп иткән начар гамәлләренең нәтиҗәсе булып тора. Аллаһ Тәгалә Көрьәндә әйтә: **“Кешеләрнең куллары кәсеп иткән гамәлләре сәбәпле җир өсте вә диңгездә яманлык таралды, кылган кайсыбер начар эшләренең нәтиҗәсен татысыннар өчен, бәлки яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар”.** (“Әр-Рум” сүрәсе, 41-нче аять).

Әмма бу бәла-казалар кешеләрнең яман гамәлләренә карата тулы җәза түгел, ә кайбер эшләре өчен генә килә. Шул ук вакытта, мондый бәла-казаларның төп максаты – кешеләрне җәзага тарту түгел, ә акылга килсеннәр һәм туры юлга кайтсыннар дип Аллаһ Тәгаләдән җибәрелә.

Имам Ибн әль-Къаййим әйткән: “*Сынауларның төп асылы кешеләрне җәзалау түгел, ә аларны төзәтеп туры юлга кайтару*”. (“Әл-Мүдхиш”, 86).

Аллаһ Тәгалә әйткән: **“Сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар, үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, ә Аллаһ гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер”.** (“Әш-Шүра” сүрәсе, 30-нчы аять).

Имам Ибн әль-Къаййим әйткән: “*Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзенең колларын төрле сынаулар һәм бәлалар җибәреп төзәтмәсә – алар тәкәббер залимнәргә әйләнерләр иде*”. (“Зәдү-л-Мәгәд”, 4/195).

Шулай ук, бер мөһим мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк – гөнаһларның нәтиҗәсен бу дөньяда яшәгәндә гөнаһ кылучы үзе генә түгел, ә аның белән бергә яшәгән тәкъва кешеләр дә татыйлар. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Зарары фетнәне булдыручыга гына түгел, бәлки барыгызга да төшә торган фетнәдән куркыгыз”.** (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 25-нче аять).

Ибн Гәббәс رضي الله عنهما [3] әйткән: “*Аллаһ Тәгалә мөэминнәргә тирә-юньдә баручы начарлык белән килешмәскә боерган, әгәр дә алар моңа салкын карасалар – начарлык кылучыларга да, начарлыкка катышы булмаганнарга да Аллаһның җәзасы төшәчәк*”. (“Әл-Бәгъауи”, 3/346).

Гәди ибн Гүмәйр رضي الله عنه исемле сахәбәдән риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Аллаһ бер кешеләрне башкалар аркасында җәзага тартмый, әгәр дә инде беренчеләре тирә-юньдә баручы начарлыкны, мөмкинчелекләре булып та, инкяр итми башласалар, шул чакта Аллаһ барчасын да газабка тартачак”*** – дигән. (Әхмәд 4/192, Ибн Әби Шәйбә 2/168, Ибн әл-Мүбәрәк “Әз-Зүһд” китабында 1352. Хәдисне Ибн Хәҗәр һәм Шүгәеб әл-Әрнәут кабул итәрлек (хәсән) диделәр. “Фәтхүл-Бәри” 6/13, “Тәхриҗ әл-Мүснәд” 17720 китапларын кара).

Гәбдуллаһ ибн Гүмәр رضي الله عنهما сөйләгән: “*Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ безгә мөрәҗәгать итте:* ***“Йә мөһәҗирләр[4]! Кешеләр биш нәрсә белән сыналачак, һәм мин Аллаһтан сезнең боларны күрүегездән саклавын сорыйм. (1) Әгәр дә җәмгыятьтә зина таралса, хәтта кешеләр фәхеш эшләрне ачык эшли башаласалар, алар арасында элек булмаган эпидемияләр һәм ачлык таралачак. (2) Әгәр дә алар үлчәүләрендә алдалый һәм киметә башласалар, аларга корылык, азык-төлек җитмәү һәм дәүләт башлыгының золымлыгы килер. (3) Әгәр дә малларыннан зәкәт бирүне туктатсалар, яңгырдан мәхрүм булырлар. Җәнлекләр булмаса, бөтенләй дә яңгырсыз калырлар иде. (4) Әгәр дә Аллаһ һәм Аның рәсүле белән килешүләрен бозсалар, Аллаһ Тәгалә читтән булган дошманнарын өсләреннән хуҗа итеп куяр. Аларга тиешле булганны тартып алырлар. (5) Әгәр дә дәүләт башлыклары Аллаһ Китабы белән хөкем итмичә башка төрле Аллаһ иңдермәгән хөкемнәргә иярсәләр, һичшиксез, Аллаһ Тәгалә араларына дошманлык салыр”.*** (Ибн Мәҗәһ 4019, әл-Хәким 2/126, әл-Бәззар 2/268. Хәфиз әл-Хәйсәми һәм Хәфиз әл-Бүсыри хәдисне тапшыручыларны ышанычлы диделәр, ә шәех әл-Әлбәни хәдисне “хәсән” дип атады. “Мәҗмүг аз-зәүәид” 5/320, “Әл-Итхәф” 7/445, “Сахих әл-Җәмиг” 7978 китапларын кара).

Моннан кала, кешеләр Аллаһның нигъмәтләреннән үзләренең Аллаһка карышулары һәм бу нигъмәтләр өчен Аңа шөкер итмәүләре сәбәпле мәхрүм калырга мөмкиннәр. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртми, ул кавем үзләрен үзгәрткәнгә чаклы. Әлбәттә, Аллаһ ишетүче вә белүче”.** (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 53-нче аять).

Имам Әл-Бәгъауи бу аятьнең тәфсирендә әйткән: “*Кешеләр Аллаһ биргән нигъмәтләргә шөкер итсәләр һәм көферлек кылмасалар, Аллаһ Тәгалә аларны бу нигъмәтләрдән мәхрүм итми. Әгәр дә инде үзләренең хәлләрен капма-каршыга үзгәртсәләр, шул чакта Аллаһ Тәгалә дә алардан Үзенең нигъмәтләрен ала башлый*”. (“Мәгәлим әт-Тәнзил”, 3/368).

---

[3] “Аллаһ аңардан разый булсын” дигән мәгънәдәге сүзләр.

[4] “Мөһәҗирләр” дип Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылган сахәбәләрне атыйлар. [Тәрҗемәчедән].

Аллаһ шулай ук әйтте: **“Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул кавем үз хәлен үзгәрткәнчегә чаклы. Вә әгәр бер кавемгә Аллаһ зарар бирүне теләсә, ул зарарны тотып калучы юк, вә аларга Аллаһтан башка ярдәм бирүче хуҗа булмас”.** (“Әр-Рагд” сүрәсе, 11-нче аять).

Гәбдүррахмән әс-Сәгди бу аятьне тәфсир кылганда әйтә: “*Әгәр дә кешеләр иман урынына көферлекне, Аллаһка буйсынуга – Аңа карышуны, шөкер итүгә - тәкәбберлекне сайламасалар, Аллаһ беркайчан да алардан Үзенең нигъмәтләрен һәм дөнья иминлеген алмый. Әгәр дә инде моңа каршы юлны сайласалар, шул чакта гына бу нигъмәтләрдән мәхрүм була башлыйлар. Һәм, киресенчә, кешеләр Аллаһка карышуны калдырып Аңа буйсына башласалар – Ул аларны төрле бәлалардан коткара, иминлек, сөенеч һәм башка нигъмәтләрен бирә*”.

Имам Әхмәд, тапшыручыларын искә алып, шундый хәбәр китерә – Бәнү Үмәййә хәлифләренең ашлык амбарларында финик төше зурлыгындагы бодай бөртекләре белән тулган капчык табылган, капчыкның тышына “*Мондый бодай гаделлек заманында үсә иде*” дип язылган булган.

Шуңа күрә дә Имам ибн Тәймийә әйткән: “*Әгәр дә мөселманнар зәгыйфь, ә дошманлары алардан көчлерәк икән – бу мөселманнарның гөнаһлары сәбәпле*” – дигән. (“Әл-Җәвәб әс-сахих”, 6/450).

Димәк, әгәр дә кешеләр белән төрле бәла-казалар, азык-төлек җитмәү, уңышның начар булуы һ.б. була башласа, бу хәлләр кешеләрнең гөнаһлары белән бәйле. Һәм монда кешеләрнең бөтенесе дә гөнаһка керүе шарт түгел, ягъни аларның бер өлеше гөнаһлар кылса, ә калганнары моңа дәшмәсәләр, хәтта шул да җитә.

Әгәр дә инде бәла-каза хосусый, ягъни аерым бер кешегә генә кагыла икән, монда да ике сәбәп була ала:

Беренче һәм төп сәбәбе – шулай ук кешенең гөнаһлары, моңа дәлил булып алдан китерелгән аять-хәдисләр тора. Шуларга өстәп башка махсус дәлилләр дә китерергә була.

Мәсәлән, Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһтан, әгәр казадан бер кайгы ирешсә, бу кайгы үзеңнең кимчелегеңнәндер”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 79-нчы аять).

Ибн әль-Къаййим әйтә: “*Әлеге аятьтә бик күп файдалар бар, шуларның берсе – Аллаһның Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ өммәтен кисәтүе. Аллаһ Тәгалә аның пәйгамбәрлегенә Үзе шәһадәт китерә, ләкин тормышында күңеле теләмәгән берәр хәл булса – бу үзеңнән дип кисәтеп тә куя. Димәк, калган кешеләр турында ни дияргә?!*”. (“Шифә үл-Гәлил”, 165).

Ә пәйгамбәребез ﷺ болай дигән: ***“Хәтта кан тамырлары кысылуы да, күз кабагы тартылуы да кешенең гөнаһлары сәбәпле. Әмма шуңа да карамастан, Аллаһ кешене бик күп бәлалардан имин кыла”.*** (Әт-Тәбәрани “Әс-Сагъир” 1053, Әбү Нүгәйм “Әхбәру Асбәһән” 2/247. Әд-Дыя әл-Мәкъдиси, әл-Мүнәүи һәм әл-Әлбәни хәдиснең дөреслеген раславдылар. “Әт-Тәйсир” 3/296, “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 2215 китапларын кара).

Сәүбән رضي الله عنه исемле сахәбәдән хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Чынлыкта, кеше үзенең кылган гөнаһы аркасында ризыгыннан мәхрүм була”*** – дигән. (Әхмәд 5/277, Ибн Мәҗәһ 90, 4022, Ибн Хиббән 872, әт-Тәбәрани “Әд-Дүгә” 31. Ибн Хиббән, әл-Мүнзири, әл-Гиракъи, әл-Бүсыри, Ибн Мүфлих, Ибн Бәз, Шүгәеб әл-Әрнәут һ.б. хәдиснең дөреслеген расладылар. “Әт-Тәргъиб” 3/294, “Мисбәх әз-зүҗәҗә” 41, “Әл-Әдәб әш-шәргия” 1/409, “Фәтәүә Ибн Бәз” 24/242, “Тәхкъик Мүшкил әл-әсәр” 8/79, “Тәхриҗ әз-Зүһд” 1/159, “Тәхкъик әд-Дәә үәд-Дәүә” 12 китапларын кара).

Ибн әль-Къаййим әйткән: *“Шуны белергә кирәк – Аллаһка карышу һәм гөнаһлар, һичшиксез, кешегә зарар китерә, калебкә – тәнгә агу эләккән кебек, зыян сала. Аллаһка буйсынмау һәм гөнаһ кылудан кала башка сәбәпле, дөньяда һәм ахирәттә, берәр яманлык һәм бәла табылырмы икән?!”.* (“Әл-җәвәб әл-кәфи, 99”).

Гөнаһлар арасында иң начары булып көферлек һәм ширекнең төрләре тора. Кызганычка каршы, хәзерге заманда болар мөселман өммәтендә дә киң таралган.

Гыймран ибн Хүсайн رضي الله عنه исемле сахәбәдән хәбәр ителә: “*Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ бер кешенең кулында сары йөзек күрде һәм аннан “**Бу нәрсә?**” дип сорады. Теге кеше “Мин аны миндә зәгыйфьлек булмасын дип киеп йөрим” – дигән. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: “**Сала күр аны, бу сиңа зәгыйфьлегеңне арттыра гына. Әгәр дә син шул йөзекне кигән хәлдә вафат булсаң, беркайчан да уңышка ирешә алмаячаксың!**”* – дигән*”.* (Әхмәд 4/445, Ибн Мәҗәһ 3531. Ибн Хиббән, әз-Зәһәби, әл-Бүсыри, әс-Сәффәрини, Ибн Бәз, Гәбдулкъадир әл-Әрнәут хәдиснең дөреслеген расладылар. “Мисбәх әз-зүҗәҗә” 4/77, “Шәрх сүләсият әл-Мүснәд” 2/465, “Тәхриҗ әхәдис мүнтәкъада фи Китәб әт-Тәүхид” 15-20 китапларын кара).

Шәех Сөләйман ибн Гәбдуллаһ Әли әш-Шәех әйткән: “*Әгәр дә берәр кем: “Әлеге юк-бар әйбернең берниндиди дә тәэсире һәм йогынтысы юк бит, ә ни өчен соң пәйгамбәребез ﷺ “**бу сиңа зәгыйфьлегеңне арттыра гына**” дигән?” – дип сораса, моңа – Аллаһ әлбәттә белүчерәк – болай дип җавап бирергә була: зәгыйфьлек арту ширек гамәле кылган өчен Аллаһтан җәза буларак киләчәк. Кеше үзенә зәгыйфьлек килмәсен дип шушы әйберне тагып куйгач, аңарга теләгәненә капма-каршысы белән җәза бирелде*”. (“Тәйсирүл-Гәзизил-Хәмид”, 1/308).

Йә мөселман өммәте, пәйгамбәребезнең ﷺ ***“бу сиңа зәгыйфьлегеңне арттыра гына”*** дигән сүзләре турында уйланыгыз. Бу сүзләрдән без ширекнең барча төрләре, хәтта чынлыкта сәбәп булмаган нәрсәне сәбәп дип исәпләп кече ширек кылу да, зәгыйфьлекне арттырганын гына күрәбез. Әгәр дә шушы юк-бар әйберне шундый

ышану белән тагып йөрү мөселманга бары зәгыйфьлек кенә өстәгәч, күп мөселман илләрендә таралган кабер әһелләреннән һәм вафат булган әүлияләрдән дога сорап олы ширек кылу турында ни дияргә?!

Әлеге гомуми кагыйдәдән чыгарма булып пәйгамбәрләр һәм тәкъва кешеләр белән була торган вакыйгалар тора. Аллаһ Тәгалә мондый кешеләрне сайлап ала һәм аларга төрле сынаулар бирә, изге гамәлләр кылуда үрнәк итеп куйган кебек, кайгыларда, бәла-казаларда һәм төрле авырлыкларда сабырлык күрсәтүләре белән дә башкаларга үрнәк итеп куя.

Димәк, икенче сәбәп – сынау һәм имтихан. "*Кешеләр арасында кемнәр ешрак сынала?*" дип сорау бирелгәч, пәйгамбәребез ﷺ: ***"[Иң ешрагы] – пәйгамбәрләр, аннан соң аларга [иманнары белән] якынрак булганнар, аннан соң икенчеләренә якынрак булганнар. Кеше үзенең иман дәрәҗәсенә карап сынала: әгәр дә динендә нык булса, сынаулары да арта, әгәр дә динендә зәгыйфьлек булса, сынаулары да шул дәрәҗәсенә карап бирелә. Һәм кеше төрле югалтуларга һәм бәла-казаларга дучар ителер, хәтта җир өстендә гөнаһларыннан арынган хәлдә атлар"*** – дип җавап биргән*"*. (Әт-Тирмизи 2/64, Ибн Мәҗәһ 4023, Ибн Хиббән 2901. Сахих хәдис. "Әс-Силсилә әс-Сахихә" 143 китабын кара).

Тагын башка хәдисне дә китерергә була, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзенең колына югары дәрәҗә тели икән, әмма бу кешенең гамәлләре моңа ирешерлек булмаса, шул чакта Аллаһ аңа тәнендә, баласында яки малында төрле сынаулар бирә. Шуннан соң тиешле сабырлыгын җибәреп, Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә аны Үзе тәкъдир кылган шул югары дәрәҗәгә күтәрә".*** (Әхмәд 5/272, Әбү Дәүд 3090. Әл-Мүнәүи һәм әл-Әлбәни хәдиснең дөреслеген расладылар. "Әс-Силсилә әс-Сахихә" 1599 китабын кара).

Монда мөселманнар арасында да таралган бер хаталы карашка игътибар итәргә кирәк: башка мөселманнарның төрле чирләргә, кыенлыкларга һәм авыр хәлләргә дучар булганын күреп, алар бу мөселманнар турында начар уйлый башлыйлар, ягъни гөнаһлары аркасында Аллаһтан килгән җәза дип исәплиләр. Чынлыкта җәза булса да, әлеге очракта бу – Аллаһның аларга карата рәхимлеген, яратуын күрсәтә, чөнки Ул аларны шул сынаулар аша гөнаһ кылудан саклый һәм арындыра. Билгеле булганча, әгәр дә Аллаһ Тәгалә кешегә яхшылык теләми икән – аңа җәза бирүне Кыямәт көненә калдыра.

Алдан әйтелгәнне гомумләп, шәех Мөхәммәд ибн Салих әл-Гүсәймин бу мәсьәләгә карата аңа бирелгән сорауга яхшы җавап бирде, ул әйтте: "*Аллаһ Тәгаләнең* **"Сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар, үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер"** (Көръән 42:30) *дигән сүзләре Аның* **"Кешеләрнең куллары кәсеп иткән гамәлләре сәбәпле җир өсте вә диңгездә яманлык таралды"** (Көръән 30:41) *дигән сүзләренә охшаш. Димәк, бәлаларның сәбәбе булып гөнаһлар тора. Һәм бу бәлалар*

*аерым шәхескә генә кагылган яки барча җәмгыятькә таралган булырга мөмкиннәр, сәбәпләре дә, шулай ук, шәхси яки гомуми була ала. Моңа дәлил итеп Аллаһның:* **“Зарары фетнәне булдыручыга гына түгел, бәлки барыгызга да төшә торган фетнәдән куркыгыз”** *– дигән Сүзләрен китерергә була.* (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 25-нче аять).

*Кеше үзенең гөнаһлары аз яки алар зур гөнаһлар түгел дип уйларга мөмкин, хәтта, ул гөнаһ эш кылса, шунда ук тәүбәгә киләдер. Шуңа күрә, әгәр дә аңа бәла-казалар ирешсә, ни сәбәпле килделәр икән дип аптырап кала. Бу бәлаларга, бәлки, тирә-юньдәге кешеләрнең гөнаһлары сәбәп булгандыр, алдан китерелгән аятьтә кебек:* **“Зарары фетнәне булдыручыга гына түгел, бәлки барыгызга да төшә торган фетнәдән куркыгыз”.** (“Әл-Әнфәл” сүрәсе, 25-нче аять).

*Шулай ук, мөһим мәсьәләгә дә игътибар итәргә кирәк: кешенең үзе турында “минем гөнаһларым юк” дип фикер йөртүе дә бәла-казаларга китерә. Чөнки мондый фикер йөрткән кеше горурга әйләнә, үзенең гыйбадәте белән Аллаһка яхшылык эшлим дип уйлый башлый. Шуннан ул “мин бит мондый җәза яки бәла килерлек берни дә кылмадым” дип Раббысына мөрәҗәгать итә. Кешенең үзе турында гөнаһсыз дип уйлавы бик зур хата булып тора. Үзенең гөнаһсыз булуы турында фикер йөртүче кеше харап булды, чөнки ул берничек тә гөнаһсыз була алмый. Кеше үзенең урынын белергә тиеш, чөнки гөнаһлардан беркем дә имин түгел.*

*Әгәр дә берәр кем “Ә бит пәйгамбәребезгә дә ﷺ бәла-казалар килгән?!” – дип сорау бирсә, без аңа: әйе, әлбәттә, пәйгамбәребезгә дә ﷺ бәла-казалар килде, әмма аңа бу бәлалар Аллаһ каршындагы дәрәҗәсен күтәрер өчен бирелде, чөнки пәйгамбәребез ﷺ һәрбер хәерле сыйфатта югары дәрәҗәгә иреште. Ягъни мәхлүкләргә*[5] *хас булган һәрбер сыйфатның иң камил ноктасына җитте. Бу сыйфатлар арасында сабырлык күрсәтү дә бар, ә сабырлык ачыклансын өчен ниндидер вакыйгалар булырга тиеш. Шуңа күрә дә, пәйгамбәребез ﷺ Исламга өндәү юлында төрле авырлыклар һәм югалтулар кичерде. Кешеләр аның чакыруын кире кактылар, ялганлыкта гаепләделәр, аны сихерче, шагыйрь, мәҗнүн дип атадылар. Хәтта Кәгбәтуллаһ каршында сәҗдә кылганда аркасына дөянең эчке әгъзаларын алып килеп аттылар. Һәм ул бу сынауларга һәм газапларга сабыр итте.*

*Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ авыртуны безгә караганда ике тапкыр катырак тойган, бер хәдисендә:* ***“Чынлыкта, мин авыртуны сезнең икегез кичергән кебек тоям”*** *– дигән.* (Әл-Бохари 5648, Мөслим 2571).

*Хәтта, үлем түшәгендә ятканда да ул башка кешеләр тоймаган авырлыклар аша үтте. Болар барсы да ни өчен соң аңа килгән? Әлбәттә, Аллаһның әмерләрендә һәм тыюларында, Ул биргән бәлаларда һәм авырлыкларда сабырлыкның иң югары баскычына ирешсен өчен бирелгән.*

---

[5] Аллаһның бар иткән затлары.

*Шуңа күрә, пәйгамбәребез ﷺ кичергән бәлалар – аңа сабырлыкны тормышка ашырып, бу сыйфатның иң югары дәрәҗәсенә ирешеп, сабыр булучы һәм шөкер итүче дигән сыйфатларга ирешсен өчен бирелгән. Пәйгамбәребез ﷺ шөкер итүдә дә иң югары дәрәҗәгә менгән, хәтта озак итеп төнге намазлар укып, аяклары шешә һәм табаннары ярыла торган булган. Һәм инде аннан: "Нигә син үзеңне шулай җәфалыйсың?" – дип сорагач, ул:* ***"Миңа Аллаһның рәхмәтле колы булырга кирәкми мени?"*** *– дигән.* (Әл-Бохари 4837). *Шулай итеп, ул сабыр итүдә дә һәм шөкерле булуда да иң биек дәрәҗәгә ирешкән, Аллаһның аңа мактавы һәм сәламы булсын*". ("Ликъа әл-бәб әл-мәфтүх", 157).

## ЧИРЛӘРГӘ, БӘЛА-КАЗАЛАРГА ҺӘМ АВЫРЛЫКЛАРГА КАРАТА МӨНӘСӘБӘТ.

Әгәр дә мөэмин кеше Аллаһ Тәгаләнең хөкемнәренә һәм тәкъдиренә карaса, шул ук вакытта, Аның камил хикмәт һәм һәр нәрсәне чолгап алган киң рәхмәт Иясе булуын таныса һәм Аның эшләрендә бернинди дә кимчелек булмаганын аңласа, шул чакта кешенең күңеле тынычланып үз урынына кайтачак һәм ул Раббысының тәкъдире белән риза булачак.

Шулай итеп, кеше ахирәт Җәннәтенә ирешкәнче үк, инде бу дөньяда ук җәннәттә яши башлаячак. Шуңа да имам ибн Тәймийә әйткән: "*Бу дөньяда җәннәт бар, кем аңа керми, шул ахирәттә дә Җәннәткә ирешә алмас*" – дигән. ("Мәдәриҗ әс-сәликин").

Ничек шулай булмасын икән, мөэмин кеше пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләренә инанган бит: ***"Мөэминнең хәле бик гаҗәптер! Аның һәрбер халәте яхшылык, һәм мөэминнән кала бу башка беркемгә дә бирелмәгән. Әгәр дә аңа берәр сөенеч килсә, ул Аллаһка шөкер итә, һәм бу аның өчен яхшылыкка әверелә. Әгәр дә инде аңа берәр көенеч килсә – сабырлык күрсәтә, һәм монсы да аңа яхшылык белән тәмамлана".*** (Мөслим, 2999).

Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ шулай ук әйткән: ***"Мөэмин ир‍гә һәм мөэминә хатынга тәннәренә, малларына һәм нәсел-балаларына төрле сынаулар килүдән туктамас, хәтта үзләренең Раббыларын гөнаһлардан чистарынган хәлдә очратканчыга кадәр"*** – дигән. (Әхмәд 2/450, әл-Бохари "Әл-әдәб әл-мүфрад" 494 китабында, әт-Тирмизи 2399. Сахих хәдис. "Әс-Силсилә әс-Сахихә" 2280 китабын кара).

Әбү Сәгыйд әл-Худри һәм Әбү Һүрайрадан رضي الله عنهما хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Мөселманга нинди генә авырлык килмәсен, булсынмы ул талчыгу, чир, борчылу, төшенкелек, күңелсезлек, кайгы, хәтта энә-шырпы кадалу – Аллаһ боларның барсы өчен дә аның нindидер гөнаһларын гафу итәчәк".*** (Әл-Бохари, 5641).

Әнәс ибн Мәлик رضي الله عنه җиткерә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзенең колына яхшылык теләсә, инде бу дөньяда ук аны җәзага тарта, ә инде аңа яхшылык теләмәсә, җәзасын Кыямәт көненә калдыра”*** – дигән. (Әт-Тирмизи 2396, Ибн Мәҗәһ 4031. Имам әт-Тахәви һәм шәех әл-Әлбәни хәдиснең дөреслеген расладылар. “Шәрх мүшкил әл-әсәр” 2050, “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 1220 китапларын кара).

Әл-Гәзизи әйткән: “*Ягъни, барча гөнаһлары өчен ахирәттә тулы җәза алсын дип, Аллаһ аңа гөнаһы өчен бу дөньяда җәза бирми*” – дигән. (“Сираҗ әл-мүнир”, 1/88).

Моны аңлатып, шәех Сөләйман ибн Гәбдуллаһ болай дигән: “*Бу хәлне аңлау – кешене һәрвакыт сәламәт булу теләгеннән кайтара, чөнки үзенең саваплы гамәлләре өчен ул инде бу дөньяда ук әҗерен алып бетергән булырга мөмкин. Ә Аллаһ Тәгалә Үзенең дошманнарын бу дөньяда җәзага тартырга яратмый һәм, шулай ук, Үзенең тәкъва колларына да бу дөньяда әҗерләрен бирергә теләми. Әмма аларның әҗере итеп, Аллаһ Тәгалә аларны Үзе янына урнаштырыр һәм ризалыгын бирер, Аллаһ Көрьәндә әйткәнчә:* **“Чынлыкта, тәкъва булучылар җәннәтләрдә татлы елгалар янындадыр. Хак булган изге мәҗлестә булырлар, һәр нәрсәгә көче җитүче Аллаһ Тәгалә хозурында”.** (“Әл-Къамәр” сүрәсе, 54-55 нче аятьләр)”.

Әбү Һурайрадан رضي الله عنه хәбәр ителә, бервакыт чүлдә яшәүче бер гарәп килгән һәм пәйгамбәребез ﷺ аңа сорау биргән: ***“Синдә берәр кайчан бизгәк[6] булганы бармы?”.*** Теге кеше: “*Ә нәрсә соң ул бизгәк?*”– дип сораган. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***“Тире белән ит арасында тән кызу”*** – дигән. Теге кеше: “*Юк*”– дип җавап биргән. Шуннан пәйгамбәребез ﷺ аннан тагын сораган: ***“Ә башың авыртканы булдымы?”*** – дигән. Бу кеше янә: “*Ә нәрсә соң ул баш авыртуы*”– дип сораган. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***“Баш эчендә басым ясап, тир бәреп чыгаручы көч”*** – дип әйткән. Һәм бу кеше янә: “*Юк*”– дип җавап биргән. Шуннан, бу кеше киткәч, пәйгамбәребез ﷺ: ***“Кемнең җәһәннәм әһеленнән булган кешене күрәсе килсә, әлеге кешегә карасын”*** – дигән. (Әбү Дәүд 3089, әл-Бохари “Әл-әдәб әл-мүфрад” 495 китабында. Шәех әл-Әлбәни хәдиснең дөреслеген раслады).

Моны аңлатып шәех Сөләйман ибн Гәбдуллаһ болай дип әйткән: *“Бу хәдистән без, кешеләр арасында киң таралган фикергә карамастан, мөэминнең тормышында очраучы төрле бәлалар һәм сынауларның кеше өчен яхшы билге булуын күрәбез. Шулай ук, хәдистә бер дә авырмыйча, һәрвакыт сәламәт булудан куркырга кирәклеген һәм моның начар билге булуын аңлыйбыз. Тагын бу хәдистә Аллаһка өметле булырга, Аңа эшләреңне тапшырып тәүәккәл кылырга, Аның тәкъдире белән тормышыңда төрле теләмәгән вакыйгаларга очраганда Аллаһ турында һәрвакытта да яхшы уйларга кирәклегенә күрсәтмә бар. Шулай ук, монда Аллаһның:* **“Бәлки сезгә яман булып күренгән әйбер – сезнең өчен хәерледер. Ә, бәлки, сез яраткан һәм теләгән әйбер – сезнең өчен ямандыр. Сезгә нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы икәнлекне**

---

[6] Бизгәк – лихорадка.

**Аллаһ белә, әммә сез белмисез”** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 216-нчы аять) – *диган Сүзләренә дә күрсәткеч бар*”. (“Тәйсирүл-Гәзизил-Хәмид” 1033).

Имам әл-Бохариның “Сахих” хәдисләр җыентыгында пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисе килә, ул әйткән: ***“Кемгә Аллаһ яхшылык тели, шуңа нинди дә булса авыру килер”*** – дигән. (Әл-Бохари, 5645).

Моннан киресен дә аңларга була – әгәр дә кешегә бернинди дә хасталык килми икән, димәк, Аллаһ аңа яхшылык теләми. Ягъни, ул һәрвакытта да нык сәламәт булып, беркайчан да авыртуга һәм төрле бәлаларга дучар булмыйча яши. Әмма беләбез, пәйгамбәребез дә ﷺ авырта торган булган һәм сызлауны башка кешеләргә караганда ике тапкыр көчлерәк тойган. Күп кешеләр дәвамлы сәламәтлек һәм төрле чирләрдән имин булу Аллаһның зур бүләге дип уйлыйлар, ягъни Аллаһ моның белән кешегә яхшылык тели, аның гамәлләренә ризалык белдерә дип фикерлиләр. Әмма пәйгамбәребез ﷺ мондый кеше турында: ***“Кемнең җәһәннәм әһеленнән булган кешене күрәсе килсә, әлеге кешегә карасын”*** – дип әйтте.

Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Кеше төрле югалтуларга һәм бәла-казаларга очраудан туктамас, җир өстендә үзенең гөнаһларыннан чистарынган хәлдә атлый башлаганчыга кадәр”*** – дигән. (Ибн Мәҗәһ 4023, Ибн Хиббән 2901. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 143 китабын кара).

Имам ибн Тәймийә әйткән: “*Бәла-казалар һәм күңелсезлекләр чынлыкта яхшылык булып торалар, чөнки алар кешене гөнаһлардан чистарталар һәм сабырлыгын чыныктыралар, шул сабырлык күрсәтү аша кеше зур әҗер-савапларга ия булачак. Алар кешене Аллаһка дога белән кайтуга, Аның каршында түбәнчел булуга, Аллаһ бар кылган затлардан бәйсезлеккә һәм башка хәерле нәтиҗәләргә китерәләр. Кешегә төрле бәла-казалар һәм борчулар килү ягыннан карасак, Аллаһ болар аша гөнаһлардан арындыра, билгеле булганча, бу үзе бер зур хәерле нәтиҗәдер. Әгәр дә кеше Аллаһ Тәгалә куйган чикләрдән чыгып начар гамәлләр кылса, аңа бу дөньяда төрле бәлалар һәм югалтулар җибәреп, Аллаһ аның ахирәттәге җәзасын җиңеләйтә. Шул сәбәпле, бәлалар һәм кайгылар, чынлыкта, Аллаһның рәхмәте һәм барча җан ияләренә карата яхшылыгы булып тора, иллә-мәгәр бу бәлалар килгәннән соң алдагы гөнаһларына карата тагын да зуррак гөнаһлар кыла башлаучылардан кала. Бу очракта, килгән бәла-казалар алар өчен яхшылыкка түгел, ә диннәре ягыннан яманлыкка әйләнә.*

*Чынлыкта, кешеләр арасында шундыйлары бардыр, аларга фәкыйрьлек, авыртулар яки ачлык килсә – зур көенечкә калалар, ачулары чыгып икейөзлелек күрсәтәләр, шуның белән җан һәм калеб чирләре белән авырый башлыйлар. Мондыйлар, я ачыктан-ачык көферлеккә төшәләр, я Аллаһның әмерләрен калдырырга һәм гөнаһ кылырга тотыналар, шул сәбәпле диннәре аяныч хәлгә кала. Шуңа күрә, бәлалар һәм күңелсезлекләрнең нәтиҗәләре шундый халәткә китергәч, болар өчен бәла-казалар*

*белән сыналуга караганда иминлектә булу яхшырак. Әгәр дә бәла-казалар кешене сабырлыкка һәм Аллаһка буйсынуга китерәләр икән, мондый кешенең дине өчен бу сынаулар яхшылык булып кайта.*

*Шуңа күрә дә инде, Аллаһның бу гамәле (кешеләргә бәла-каза җибәреп тәкъдир кылуы) Үзенең җан ияләренә карата мәрхәмәтлелек күрсәтүе булып тора, һәм Ул моның өчен мактауга лаеклы. Әгәр дә моңа Аллаһка буйсыну һәм Аңа күндәмлек тә иярә икән, бу Аллаһның шушы бәла белән тәкъдир кылган бәндәсенә тагын бер рәхмәте була. Әгәр дә инде моның сәбәпле берәрсе гөнаһка керә башлый икән, шуның белән бит кешеләр бәла-каза вакытында яки иминлектә бер-берсеннән аерылалар.*

*Шулай итеп, кемгә сынау белән тиешле сабырлыгы да килгән икән, шул хәерлеккә ирешә һәм гөнаһларыннан чистарынып Аллаһның рәхмәтен ала. Ә Раббысын зурлап һәм мактап, үзенә карата Аның мактавына лаек була. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:* **“Бәлә-казаларга риза булып, сабыр итүче мөэминнәргә Раббыларыннан мактау һәм рәхмәт булыр. Шуның белән бергә алар туры юлга күнүчеләр”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 157-нче аять).

*Шуның аша кеше Раббысыннан гафу ителүгә һәм дәрәҗәсе күтәрелүгә ирешә, әлбәттә, болар бик зур хәерлектер.*

*Шуңа күрә, бәла-казалар килгәндә сабыр булу тиешледер. Кем шуны үти, ягъни сабыр булып чыдамлык күрсәтә, шул санап үтелгәннәрнең барысын да алачак*”. (“Мәҗмүгүл-фәтәүә” 17/26-27, кыскача).

Кайсыбер гыйлем ияләре бу сүзләргә карата болай дип әйттеләр: “*Бу аңлатмадан без үзебезнең динебезне тиешенчә, дөрес итеп, аңлап бетермәгәнебезне күрәбез. Әлбәттә, Аллаһ Тәгалә рәхим-шәфкать кылган кешеләрдән кала. Чөнки динебезне дөрес аңласак – Аллаһның безгә карата һәр хөкеменә һәм тәкъдиренә рәхмәтле булыр идек. Хәтта моңа карата кеше Аллаһның башка нигъмәтләренә караган кебек карар иде һәм шуның аша Аллаһ Тәгалә Үзенең колын Аны мактауга һәм Аның каршында түбәнчел булырга китергәнен аңлар иде. Әгәр дә без алдан әйтелгән хәдис турында дөрес фикер йөртсәк, шуны күрербез – кеше үзенең тормыш юлында сәламәтлектә һәм гаиләсендә иминлектә яшәп, малы, балалары, хатыны, иркен йорты һәм башка тышкы нигъмәтләре булып, әмма үзенең барча омтылышларын бары шулар белән генә чикләгән икән – мондый кеше Аллаһ диненең асылын аңламый. Берәр кем шундый хәлдә яши икән, бел, бу Аллаһның рәхмәте төшкән кеше түгел. Тәкъва сәләфләр*[7]*, әгәр дә аларга берәр нинди авыру яки бәла килми торса, моның өчен борчыла башлыйлар иде. Чөнки шулар аша Аллаһ Тәгалә аларның кимчелекләрен төзәтә һәм гөнаһларын*

---

7 “Сәләфләр” – пәйгамбәребез ﷺ һәм аның сахәбәләре, алардан соң килгән тәбигиннар, һәм алардан соң килгәннәр, ягъни беренче өч буын мөселманнар. Пәйгамбәребез ﷺ: ***“Иң яхшы кешеләр – минем буын, аннан алардан соң килүчеләр, аннан боларыннан соң килүчеләр”*** – дигән. (Әл-Бохари һәм Мөслим китерәләр). [Тәрҗемәчедән].

*чистартканын беләләр иде. Пәйгамбәребез ﷺ әйткән:* ***“Әгәр дә Аллаһ Үзенең колына яхшылык теләми икән, аңа җәза бирүне тотып тора”*** *– дигән, ягъни җәзасын [Кыямәт көненә] калдырып килә, ә бит, билгеле булганча, бу дөньядагы газап ахирәт газабы белән чагыштырып булмаслык җиңел. Кешегә дөньялыкта нинди генә авыр сынау килсә дә, бу ахирәттә булачак шуңа туры килүче җәза янында бик түбәндер. Аллаһ Тәгаләдән иминлек һәм тынычлык сорыйбыз”.* (“Къираа үә тәгликъ гәлә Тәйсирил-Гәзизил-Хәмид”).

Без бу хәдисләрдән һәм галимнәрнең сүзләреннән шуны күрәбез – Аллаһның Үзенең колын яратуы сәламәтлек булу, нәсел-балалар күплеге, байлык һәм башка дөнья нигъмәтләре белән билгеләнми. Әмма, чынлыкта, Аллаһның яратуы – кемгә Ул динне һәм диндә ныклык бирүе белән таныла!

Гәбдуллаһ ибн Мәсгүдтән رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Чынлыкта, Аллаһ Тәгалә сезнең арагызда ризыгыгызны бүлгән кебек, әхлагыгызны да бүлгән. Һәм, чынлыкта, Аллаһ Тәгалә бу дөньяны яраткан бәндәсенә дә, яратмагына да бирә. Әмма динне Ул, бары тик, ятратканына гына бирә! Һәм кем үзенең малын сарыф итүдә саранлык күрсәтә, дошманнарга каршы көрәшергә курка һәм төнге намазларны үти алмый – шул күбрәк “Сөбхәнә-Ллаһ”, “Әлхәмдү-лиЛләһ”, “Лә иләһә иллә-Ллаһ” һәм “Әллаһү әкбәр” сүзләрен әйтсен”*** – дигән. (Әл-Исмәгили “Әл-Мүгҗәм” 1/114 китабында, Әбү Нүгәйм “Әл-Хилья” 4/166 китабында, әл-Бәззар “Әл-Бәхр әз-зәххар” 2026 китабында. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 2714 китабын кара).

Хәфиз әл-Мүнәви “Әт-Тәйсир” һәм әс-Сангәни “Әт-Тәнвир” китапларында, кеше әлеге зекерләрне күп әйтеп, бу хәдистә санап үтелгән гамәлләрне үтәгән кебек әҗер ала дигәннәр.

Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ кешегә, нинди генә авыр хәлдә калуына карамастан, һәрвакытта да бәхетле һәм Раббысының шөкер итүче колы булып калырга булышучы сәбәпкә күрсәткән.

Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә берәрегез малы һәм матурлыгы белән үзеннән югарырак кешегә карый икән, болар белән үзеннән түбәнрәк торучыга да карасын”*** – дигән. (Әл-Бохари 6490, Мөслим 2963-8).

Имам Мөслим китерә торган риваятьтә: ***“Үзегездән түбәнрәк торучыларга карагыз, югарырак булучыларга түгел, бу сезгә Аллаһ биргән нигъмәтләргә азсынып карамаска ярдәм итәр”*** – диелгән. (Мөслим, 2963-9).

## ТӘКЪДИРГӘ РИЗА БУЛУЧЫ БЕЛӘН АЛЛАҺ ҮЗЕ РИЗА.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Чынлыкта, әҗер-савап сынауның авырлыгына карап бирелә. Һәм, чынлыкта, Аллаһ берәр кавемне яратса, аларга Үзенең сынауларын җибәрә, кем ризалык күрсәтә, шуның үзенә ризалык, ә кем ачу күрсәтә – үзенә Аллаһның ачуы булыр”*** – дигән. (Әт-Тирмизи 2396, Ибн Мәҗәһ 4031, “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 146).

Пәйгамбәребезнең ﷺ бу сүзләрен аңлатып шәех Сөләйман ибн Гәбдуллаһ болай дип әйткән: *“Берәр кемгә Аллаһ Үзенең хөкеме белән ниндидер сынауны тәкъдир кылган икән һәм кеше шуны ризалык белән кабул иткән икән – аның үзенә Аллаһның ризалыгы булыр, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:* **“Аллаһ алар белән риза булды, һәм алар да Аллаһ белән риза”** (“Әл-Бәййинә” сүрәсе, 8-нче аять). *Бу – ризалык белдерүнең мөһимлеген, ягъни, Аллаһның карарына баш күтәрмичә, ачуланмыйча һәм нәфрәт күрсәтмичә калырга кирәклеген күрсәтә, пәйгамбәребез ﷺ бер кешегә әйткәнчә:* ***“Аллаһны сиңа нәрсәдер тәкъдир кылуында гаепләмә һәм шелтәләмә”.*** (Әхмәд 5/318, әл-Бәйһакъи «Әш-Шүгәб” 9714 китабында).

*Ибн Мәсгүд رضي الله عنه әйткән: “Чынлыкта, Аллаһ Үзенең гыйлеме һәм рәхмәте белән, инанганлык һәм ризалыкка тынычлык һәм сөенеч, ә шикләнү һәм ачулануга тынычсызлык һәм сагыш салган”.* (Әл-Хәннәд “Әз-Зүһд”, 535).

*Ибн Гәүн әйткән: “Килгән авырлыкларда һәм җиңеллекләрдә Аллаһның хөкеме белән риза бул. Чынлыкта, бу синең сагышыңны киметер һәм ахирәттә өмет иткән әҗерләргә якынайтыр. Һәм бел, Аллаһ колы чын ризалыкка ирешмәс, аның фәкыйрьлектәге һәм авырлыклардагы ризалыгы муллыктагы һәм иминлектәге ризалыгы белән тигез булганга чаклы. Үз эшләреңдә Аллаһтан ярдәм сорап, әмма Аның карары син көткәннән аерылганын күреп, ничек итеп шуннан ачуланырга була?! Бит, әгәр дә сиңа теләгәнең бирелсә, бу синең өчен һәлакәткә әйләнергә мөмкин. Һәм син, Аллаһның карары синең теләгәнеңә туры килсә, шуңа сөенәсең. Болар барысы да яшерен һәм сер булган нәрсәләрне белмәгәнлектән. Әгәр дә шундый хәлдә икәнсең, син үзеңә карата золымлык кыласың һәм “ризалык” төшенчәсенең чын мәгънәсен аңламагансың”.* (Ибн Әби әд-Дүньйә “Рида гәни-Лләһ” 69 китабында).

Әбү Сәгадәт пәйгамбәребезнең ﷺ ***“ә кем ачу күрсәтә – үзенә Аллаһның ачуы булыр”*** дигән сүзләре турында әйткән: *“Ачу ул – нәрсәгәдер нәфрәтләнү һәм риза булмау. Ягъни, кем Аллаһның тәкъдиренә карата нәфрәт күрсәтә, шул үзе Аллаһның нәфрәтен һәм ачуын алыр, ә бу үзе җәза кебек җитә кала. Аллаһ Тәгалә әйткән:* **“Бу шуның өчендер – алар Аллаһның ачуын китерә торган нәрсәгә иярделәр һәм Аллаһ риза булганга нәфрәт күрсәттеләр. Шул сәбәпле Аллаһ аларның гамәлләрен юкка чыгарды”.** (“Мөхәммәд” сүрәсе, 28-нче аять).

Бу аятьтән без тәкъдиргә ризасызлык белдерү олы гөнаһларга кергәнен күрәбез, хәтта, кайсыбер галимнәр бу аятьне тәкъдир белән риза булу тиешле (вәҗиб) гамәл икәненә дәлил итеп китерделәр, шулардан Ибн Гәкыль. Башка галимнәр, мәсәлән, Әл-Къады Гийяд, Ибн Тәймийә һәм Ибн әл-Къаййим ризалыкка карата – вәҗиб түгел, ә кирәкле булган күркәм гамәл (мөстәхәб) дигән фикердә булдылар.[8]

Имам ибн Тәймийә әйткән: "*Ризалык белдерүгә әмер, сабырлык күрсәтүгә карата булган әмер кебек катгый түгел, әмма ризалык турында кызыксындыра һәм мактый торган текстлар килде*" - дигән. ("Мәдәриҗ әс-сәликин", 2/171).

Ислам диненең башка зур галиме Ибн әл-Къаййим әйткән: "*Кем үзенең Раббысын тиешле рәвештә таныган һәм Аллаһның исем-сыйфатларын дөрес итеп аңлаган, шул яхшы белә: аңа килүче күңелсезлекләр һәм өстенә төшүче сынаулар акыл белән аңлап бетермәслек иксез-чиксез хәерлекләр һәм файдаларның төрләредер. Аннан да ары әйтергә кирәк, кешенең күңеленә ятмаган әйберләр ул теләгән нәрсәләргә караганда күпкә хәерлерәк. Бит яхшылыкларның күпчелек өлеше кешеләрнең күңелләре яратмаган нәрсәләрдә яшеренгән һәм, киресенчә, зыяннарның күпчелек өлеше һәм һәлакәткә илтүче сәбәпләр күңелләр яраткан әйберләрдә урын алган.*

*Әгәр дә иң хикмәтлеләрнең Хикмәтлесе, иң рәхимлеләрнең Рәхимлесе, иң гыйлемлеләрнең Гыйлемлесе, Үзенең колларына ата-аналары һәм үз-үзләренә карата да мәрхәмәтлерәк булучы, аларга күңелләре теләмәгән сынаулар җибәрә икән, димәк монда, бу сынаулар килмәгәнгә караганда, күбрәк файда бардыр. Һәм Ул боларны алар турында кайгыртып, яхшылык теләп һәм йомшаклык күрсәтеп эшли. Әгәр дә кешеләрнең үзләренә монда сайлау иреге бирелгән булса, иминлекләрен тиешенчә кайгыртырга гыйлемнәре дә, ихтыярлары да, гамәлләре дә җитмәс иде. Әмма Аллаһ Сөбхәнәһү үә Тәгалә Үзенең гыйлеме һәм рәхмәте белән аларның барча эшләрен Үзенә алган, әйе, бәлки кешеләргә кайсыбер хөкемнәр ошап бетмәсә дә. Аллаһның исем-сыйфатларына карата төпле гыйлемле кешеләр моны бик яхшы аңлыйлар һәм Аллаһның карарларына берничек тә каршы чыкмыйлар. Әмма Аллаһның Кем икәнен тиешенчә аңламаган, Аның исем-сыйфатларын белмәгәннәрдән бу хәл яшерен кала, шуңа күрә алар Аллаһның идарә итүенә һәм карарларына ризасызлык белдерәләр, Аның хикмәтен хурлыйлар һәм түбәнсетәләр, ихтыярына буйсынмыйлар, үзләренең бозык акыллары, ялган ышанулары һәм гаделсез сәясәтләре белән Аллаһның карарларына баш күтәреп чыгалар. Шулай итеп, алар Раббыларын да тиешенчә танымадылар һәм иминлеккә дә ирешә алмадылар.*

---

[8] Шулай итеп, бәла-каза килгәндә кешеләрне, дәрәҗәләре үсү тәртибендә, дүрт төрле категориягә бүлергә мөмкин:

- ризасызлык белдереп ачуы чыгучы;
- ризасызлык белдермичә сабыр булучы;
- ризалык белдерүче;
- рәхмәтле һәм шөкер итүче. [Тәрҗемәчедән].

*Әгәр дә Аллаһның колы алдан әйтелгәнне тиешенчә аңлауга килсә, ахирәткә җиткәнче, инде дөньяда ук, җәннәт тормышы белән яши башлаячак, моның рәхәтен бары мәңгелек Җәннәт рәхәтлекләре белән генә чагыштырып булыр. Чынлыкта, мондый кеше һәрвакытта үзенең Раббысына карата ризалыкта, ә ризалык – бу дөньяның җәннәте һәм Аллаһка карата гыйлеме булганнарның тынычлыгы. Чынлыкта, ризалык – җанның аңа тәкъдир кылынган белән ләззәтләнүе, чөнки бу тәкъдир аңа Аллаһның Үзенең сайлавы белән килде. Шулай ук, ризалык – ул күңел тынычлыгы, Аллаһның дини хөкемнәренә тулысынча инану һәм тапшырылу. Менә шул инде Аллаһка – Раббы буларак, Исламга – дин буларак һәм Мөхәммәдкә – рәсүл буларак канәгатьлек белдерү була. Һәм моңа ирешмәгән, иманның тәмен татымады. Ризалыкның бу дәрәҗәсе Аллаһның гаделлеген, хикмәтен, рәхмәтен һәм Үзенең колына иң яхшысын сайлый белүне төшенү белән туры килә. Кеше моны яхшырак аңлаган саен, Аллаһ белән ризалыгы да арта бара*". ("Әл-Фәүәид", 132-136).

Ибн әл-Къаййим шулай ук әйткән: "*Надан кеше үзенең хәленә зарланганда, чынлыкта Аллаһ Тәгалә хакында зарлана, бу Раббысына карата да һәм зар китерелгән кешеләргә карата да белемсезлекнең иң түбән ноктасыдыр. Бит ул Раббысын Кем икәнен тиешенчә белсә, Аңа зар китерергә башына да килмәс иде, ә, әгәр дә, кешеләрнең хакыйкый асылын аңласа, аларга зарланмас иде, бер шагыйрь әйткәнчә:*

*Үзенең хәле белән кешеләргә зарланучы,*

*Рәхимле Затка карата рәхимсезләргә зар белдерә.*

*Димәк, зарлануның өч дәрәҗәсе бар: иң түбәне – кеше Рәхимле Затка карата рәхимсезләргә зарлана (ягъни, кешеләргә Аллаһ белән зарлана); уртанчысы – Гадел Затка гаделсезләр өстеннән зарлана (ягъни, Раббысына кешеләрдән зарлана); һәм иң югарысы – үз-үзеннән Аллаһ Тәгаләгә зарлана".* ("Әл-Фәүәид", 88).

Әнәс ибн Мәликтән رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Кем Аллаһның тәкъдиренә ышанып та, Аның карарлары белән риза түгел – үзенә Аллаһтан кала башка Раббы эзләсен"*** – дигән. (Әт-Тәбәрани "Әл-Әүсат" 8366 китабында, Әбү Нүгәйм "Әхбар әл-Әсбәһән" 2/228 китабында, әл-Хатыб "Тарих Бәгъдәд" 2/227 китабында).

Әйтеп үтәргә кирәк, галимнәр арасында бу хәдиснең дөреслеге турында фикер каршылыклары бар. Мәсәлән, әл-Мүнәүи "Әт-Тәйсир" (2/443) китабында бу хәдисне дөрес дип әйтте. Әмма әл-Һәйсәми хәдисне тапшыручылар чылбырында Суһәйл ибн Әби Хәзм бар диде, аны хәдис галимнәренең имамнарыннан булган Ибн Мәгин – ышанычлы, ә калган хәдис галимнәре – зәгыйфь тапшыручы диделәр. Ә Суһәйл ибн Әби Хәзмнән кала башка тапшыручылары – "Мәҗмүгү әз-зәүәид" (7/207) исемле китапта барысы да ышанычлы дип әйтелгән.

Шулай итеп, әгәр дә әлеге хәбәр дөрес икән – ул, тәкъдирнең нинди булуына карамастан, аңа ризалык белдерүнең хупланган гына түгел, ә катгый рәвештә булырга тиешле гамәл икәнен күрсәтә.

Имам ибн Тәймийә әйткән: “*Килгән бәла һәм кайгыларга ризалык белдерүдән тагын да өстенрәк дәрәҗә – Аллаһка болар өчен рәхмәтле булу һәм шөкер итү. Һәм бу рәхмәтлелек – кешенең аңа Аллаһ Тәгаләдән бу бәла аркылы бирелгән нигъмәтләрен күрә белүдән барлыкка килә*” – дигән. (“Мәҗмүгүл-фәтәүә” 11/260).

Һәм моннан табигый сорау туарга мөмкин: алайса кешенең үзендә һәм тирә-юньдә нәрсәнедер үзгәртергә омтылуын ничек аңларга? Бит бу теләк – булган халәт белән канәгать булмауны күрсәтә.

Мәлики мәзһәбнең әвәлге имамы әл-Карафи, Аллаһның тәкъдире һәм карарына ризасызлык белдерү һәм килеп чыккан вакыйгага карата ризасызлык белдерү арасында аерманы аңлатып, болай диде: “*Тәкъдир белән тәкъдир кылынганның аермасын шундый мисал белән чагыштырып аңларга була: табиб авыруга бик тә әче дару язып биргән яки аның кулына ампутация ясарга карар кылган, ә хаста кеше: “Бу табиб бигрәк тә начар карарга килде һәм бик куркыныч ысуллар белән дәвалый. Башка берәрсе аның урынында яхшырак хәл итәр иде” – дип әйтә. Менә бу инде табибның карарына ризасызлык белдерү була, табиб мондый сүзләрне ишетсә – аңа бер дә ошамаячак, кәефе төшәчәк. Әмма, әгәр дә, авыру “бу дару бигрәк тәмсез” яки “ампутация сәбәпле бик нык сызлану кичердем” дип әйтсә, бу очракта инде ул тәкъдирнең нәтиҗәләренә карата ризасызлык белдерә, ягъни даруның әче булуына һәм ампутация сәбәпле сызлануына шикаять белдерә, табибка һәм аның дәвалау ысулларына түгел. Һәм монда табибка карата шелтә юк, бу сүзләрне ишетү дә аның күңеленә ятышсыз булмаячак, хәтта, ул үзе бу сүзләр белән тулысынча килешәчәк. Шуңа күрә, берәр кемгә сырхау килеп, ул шуның сәбәпле азап чиксә һәм сызланулар аңа авырлык китерсәләр – бу тәкъдиргә ризасызлык белдерү булмый. Әмма инде ул “бу хәлгә лаек булырлык нәрсә эшләдем соң мин, минем нинди гаебем бар” дип язмышка зарланса, менә бу очрак тәкъдиргә карата ризасызлык белдерү булачак*”. (“Әл-Фүрукъ” 8/320 китабын кара).

Әйтеп үтәргә кирәк, авырлыклар турында зарланып та, шатланып та, чынбарлыкны җиткереп тә сөйләргә була. Ә ризасызлык белдерү кешенең калебенә әйләнеп кайта, әгәр дә ул үзенең авыр халәтенә түгел, ә Аллаһның галәм белән идарә итүенә һәм Аның карарларына риза түгел икән, менә бу тыелган ризасызлык була да инде. Әмма берәр нинди авырлык турында чынбарлыкны җиткерүдә, мәсәлән, “бүген көн бигрәк эссе яки салкын” дип әйтүдә бернинди каршылык юк, әлбәттә, моның Аллаһның Үзе бар иткән галәмдәге карарлары белән канәгатьсезлек белдерүгә бәйләнеше булмаса.

Имам әл-Бохариның “Сахих” хәдисләр җыентыгында “Сырхаулар китабы”нда шундый бүлек бар, ул болай дип аталган: *“Сырхау кешегә “Мин авыртам” яки “Башым бик каты авырта”, яки “Мин үземне начарrак хис итәм” – дип әйтергә ярый, һәм, шулай ук, Көрьәндә килүче Әйюб пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) сүзләре:* **“Йә Раббым, мине сырхау вә бәла тотты, ә бит Син рәхмәт итүчеләрнең иң рәхимлесе”.** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 83-нче аять). Һәм, шуннан соң, бу бүлектә шул мәгънәдәге хәдисләр килә.

## ӘҖЕР-САВАПНЫҢ ЗУРЛЫГЫ СЫНАУЛАРНЫҢ АВЫРЛЫГЫНА ТӘҢГӘЛ КИЛӘ.

Әнәс ибн Мәликтән رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Чынлыкта, әҗер-савап сынауның авырлыгына карап бирелә. Һәм, чынлыкта, Аллаһ берәр кавемне яратса, аларга Үзенең сынауларын җибәрә, кем ризалык күрсәтә, шуның үзенә ризалык, ә кем ачу күрсәтә – үзенә Аллаһның ачуы булыр”*** – дигән. (Әт-Тирмизи 2396, Ибн Мәҗәһ 4031. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 146).

Имам Әхмәд моңа охшаган башка хәдис китерә, Мәхмүд ибн Ләбидтән رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә Аллаһ берәр кавемне яратса, Ул аларга сынаулар җибәрә. Кем сабырлык күрсәтә – аңа да сабырлык күрсәтелер, ә кем сабыр итми – шуның үзенә карата да сабырлык булмас”.*** (Әхмәд 5/428, әл-Бәйһәкъи «Шүгәб әл-имән” 9784 китабында. Хәфиз әл-Мүнзири һәм хәфиз Ибн Хәҗәр хәдиснең тапшыручыларын ышанычлы диделәр. Ә Ибн Хәҗәр әл-Хәйтәми хәдисне сахих диде. “Әт-Тәргъиб үә-т-Тәрһиб” 4/124, “Фәтхүл-Бәри” 10/108, “әз-Зәүәҗир” 1/315 китапларын кара).

Гәбдуллаһ Ибн Мәсгүд رضي الله عنه сөйләгән: *“Бервакыт мин пәйгамбәребез ﷺ янына кердем, ә ул бик көчле температурадан интегә иде һәм мин: “Бигрәк температураң югары!” – дидем, аннан: “Бу сиңа әҗер-савап ике тапкыр күбрәк бирелгәнгә шулаймы?” – дип сорадым. Ул әйтте:* ***“Әйе, һәм кайсы гына авырлык кичерүче мөселман булмасын, агач үзенең яфракларыннан арынган кебек, Аллаһ та аны гөнаһларыннан арындырыр”*** *– диде”.* (Әл-Бохари, 5647).

Шәех Сөләйман ибн Гәбдуллаһ әйткән: *“Пәйгамбәрләр әҗер-савапны иң күп алучылардан булгач, аларга бәла-каза һәм сынаулар да, калган кешеләргә караганда, күбрәк килгән. Хәдистә килгәнчә, Сәгд исемле сахәбә бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына кергән һәм* “*Кешеләр арасында кемнәр ешрак сынала?” дип сораган, пәйгамбәребез ﷺ:* ***“[Иң ешрагы] – пәйгамбәрләр, аннан соң аларга [иманнары белән] якынрак булганнар, аннан соң икенчеләренә якынрак булганнар. Кеше үзенең иман дәрәҗәсенә карап сынала: әгәр дә динендә нык булса, сынаулары да арта, әгәр дә динендә зәгыйфьлек булса, сынаулары да шул дәрәҗәсенә карап бирелә. Һәм кеше төрле югалтуларга һәм бәла-казаларга дучар ителер, хәтта җир өстендә гөнаһларыннан арынган хәлдә атлар”*** *– дип җавап биргән”.* (Әт-Тирмизи 2/64, Ибн Мәҗәһ 4023, Ибн Хиббән 2901. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 143 китабын кара).

*Кайсыбер галимнәр **“Әҗер-савап сынауның авырлыгына карап бирелә”** дигән сүзләр шуны күрсәтә – килгән бәла-казалар һәм сырхаулар өчен кешегә саваплар языла, әмма гөнаһлары кичерелми диләр. Әмма Ибн әл-Къаййим һәм башка галимнәр “бәлалар һәм чирләр өчен кешенең гөнаһлары кичерелә, ә шулар сәбәпле кеше хәерле гамәлләр дә күбрәк кыла башласа, тәүбәгә килеп Аллаһтан догалар белән ялварса, сабырлык һәм ризалык күрсәтә башласа, бу очракта ул әҗер-савапларга лаек була, чөнки аның бу гамәлләре килгән авырлыклар һәм сырхаулар сәбәпле булды” дип әйтәләр. Моңа пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисе күрсәтмә булып тора:* ***“Аллаһ каршында кешенең дәрәҗәсе зур булырга мөмкин, әмма ул бу дәрәҗәгә үзенең гамәлләре белән ирешә алмас. Һәм Аллаһ аны, шул зур дәрәҗәгә күтәргәнче, төрле күңелсезлекләр белән сынар”.*** (Әбү Яглә 4/1447, Ибн Хиббән 693. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 2599 китабын кара).

Кайсыбер гыйлем ияләре әйттеләр: *“Чынлап та, шулай булырга мөмкин – кеше Аллаһ Тәгаләдән иң югары Фирдәүс җәннәтләрен сорый, шул ук вакытта, моңа ирешерлек гамәлләр кылмый. Шулай булса да, Аллаһ Тәгалә аның догасына җавап бирә һәм бу зур дәрәҗәгә күтәрә. Әмма кеше моңа лаек булырлык гамәлләр үтәргә ашкынмагач, Аллаһ аңа бәла-каза һәм сынаулар җибәрә, шуның белән бергә тиешле сабырлыгын да бирә”.* (“Къыраа үә тәгликъ гәлә Тәйсирил-Гәзизил-Хәмид”).

Шәех Сөләйман дәвам итә: *““Килгән бәла-казалар һәм сырхаулар өчен кешегә саваплар языла, әмма гөнаһлары кичерелми” дигән фикергә галимнәр болай дип җавап бирәләр:* ***“Әҗер-савап сынауның авырлыгына карап бирелә”*** *дип әйтелгән хәдистә кешенең дәрәҗәсе, бары тик, Аллаһның әҗеренә өмет иткән хәлдә сабырлык күрсәтсә генә күтәрелә.*

*Пәйгамбәрләр (Аллаһның аларга сәламе булсын) – Аллаһның яраткан коллары арасында иң яхшылары булганлыктан, алар төрле сынауларга иң күп дучар ителделәр, һәм аларга башка беркемгә дә килмәгән авырлыклар килде. Шуның аша алар бөек әҗер-савапларга һәм Аллаһ ризалыгының иң биек баскычларына лаек булдылар. Шулай ук, бу авырлыклар – калган кешеләр алардан үрнәк алсыннар һәм аларны чиктән тыш зурлап, Аллаһка гыйбадәт кылган кебек, гыйбадәт кыла башламасыннар, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылсыннар өчен җибәрелде, чөнки пәйгамбәрләр – кешеләр иделәр, башка кешеләргә килгән кебек, аларга да төрле сынаулар, кайгылар һәм югалтулар килде.*

*Кемдер сорау бирергә мөмкин: “Ничек инде Аллаһ Тәгалә Үзенең яраткан бәндәләренә бәлалар һәм сынаулар җибәрә?”.*

*Моңа җавап йөзеннән шуны истә тотырга кирәк – беркем дә гөнаһлардан имин түгел, шуңа күрә бәла-каза һәм кайгылар, сынау булып, кешеләрне гөнаһлардан чистарталар, һәм моңа сахих хәдисләр күрсәтмә булып торалар, шулай ук,*

*“Аларны гөнаһларыннан чистартып бетергәнчегә хәтле бәла-казалар белән сынармын” – дигән иләһи сүзләр дә шуны күрсәтә.* (“Кәлиматүл-ихлас” 46, “Мәдәриҗ әс-сәликин” 1/194, “әл-Гүкъуд әд-даррия” 343 китапларын кара).

*Шулай ук, ныклы сабырлык күрсәтүче мөэмингә, кичергән сынауларның нәтиҗәсе булып, Җәннәттәге урыны күтәрелүе тора, хәдистә әйтелгәнчә:* ***“Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзенең колына югары дәрәҗә тели икән, әмма бу кешенең гамәлләре моңа ирешерлек булмаса, шул чакта Аллаһ аңа тәнендә, баласында яки малында төрле сынаулар бирә. Шуннан соң тиешле сабырлыгын җибәреп, Аллаһ Сөбхәнәһү вә Тәгалә Үзе тәкъдир кылган шул югары дәрәҗәгә күтәрә”.*** (Әхмәд 5/272, Әбү Дәуд 3090. Әл-Мүнәүи һәм әл-Әлбәни хәдиснең дөреслеген раcладылар. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 1599, 2599 китабын кара).

*Шулай ук, сынау – кешене тәүбәгә китереп Раббысына кайтара. Бит Аллаһ кешене гөнаһларыннан тәүбәгә килсен дип төрле бәла-казалар белән сыный, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:* **“Кешеләрнең куллары кәсеп иткән гамәлләре сәбәпле җир өсте вә диңгездә яманлык таралды, кылган кайсыбер начар эшләренең нәтиҗәсен татысыннар өчен, бәлки яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар”.** (“Әр-Рум” сүрәсе, 41-нче аять).

*Әгәр дә Аллаһ Тәгалә берәр кемне бәла-каза аша тәүбәгә килү белән бүләкли икән, кеше өчен бу – Аллаһ биргән иң зур нигъмәтләрнең берсе булачак. Чөнки, моның нәтиҗәсендә, кеше Аллаһ Тәгаләгә догалар белән ялвара башлый, Аның каршында түбәнчелгә әйләнә һәм әмерләренә буйсына. Шуңа күрә, Аллаһка дога белән ялвармыйча, килгән кайгыны түбәнчелек белән кабул итмәүчеләргә Аллаһ шелтә белдерә, Үзе әйткәнчә:* **“Без аларны газап белән тоттык, әмма алар Раббыларына буйсынмадылар һәм дога белән ялвармадылар”.** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 76-нчы аять).

*Аллаһка дога кылу һәм Аның каршында түбәнчел булу – иң зур нигъмәтләрнең берсе. Бу ике әйбер һәм алар алдыннан килгән сынаулар – кешенең дөрес итеп динен аңлавын күрсәтүче иң зур билгеләр булып торалар. Чөнки диннең дөреслеге ул – Аллаһка гыйбадәттә булу һәм Аңа өмет итеп тәүәккәл кылу, һәм догалар белән Аллаһтан кала башка беркемгә дә ялвармау, булсынмы ул гыйбадәт догасы, булсынмы – сорау догасы.*[9]

*Тәүбә үз эченә бер Аллаһка гына гыйбадәт кылуны һәм пәйгамбәрләренә буйсынып, Аның әмерләрен үтәүне, тыйганнарыннан тыелуны ала. Әгәр дә Аллаһ Тәгалә сине*

---

9 Галимнәр доганы ике төргә бүләләр: гыйбадәт догасы һәм сорау догасы. Сорау догасы – кеше Раббысыннан үзенең <u>теле</u> белән нәрсәдер сорый, ә гыйбадәт догасы – кеше Раббысыннан үзенең ниндидер <u>гыйбадәте аша калебе</u> белән сорый, мәсәлән, Җәһәннәмнән ерак булырга һәм Җәннәткә керергә өмет итеп намаз укый, ураза тота һ.б. Шулай итеп, әгәр дә фикерләп карасак, мөэмин-мөселман кешенең барча тормышы догадан тора, чөнки ул – булсынмы теле белән, булсынмы үзенең гамәлләре аша калебе белән Аллаһка мөрәҗәгать итә. [Тәрҗемәчедән].

*тәүбәгә кайтарган икән, димәк, син чынлап та, хак рәвештә, Аллаһка гыйбадәт кылучылардан. Син Аңа үзеңә кирәк һәм файдалы булган хаҗәтләреңне сорап, һәм, киресенчә, зыянлы нәрсәләрдән саклау сорап догалар белән мөрәҗәгать итәсең. Бу синең өчен Аллаһның иң бөек нигъмәтләренә әверелә. Ә мондый хәл, ешрак, кешегә төрле бәла-казалар килгәндә була. Һәм, әгәр дә, кеше бу нигъмәтләрне югалтулар һәм бәлалар аша ала икән, димәк, боларга Аллаһның башкалардан яраткан коллары күбрәк лаек булалар. Һәм шуңа күрә дә инде, авырлыкларга очраучылар моның өчен Аллаһка рәхмәтле булырга тиешләр".* ("Тэйсирул-Гэзизил-Хэмид" 1034-1037. Шәех Сөләйман бу сүзләрне, кыскартылган рәвештә, имам Ибн Тәймийәнең "Мәҗмүгүл-фәтәүә" 11/259-260 китабыннан китерде).

## БӘЛА-КАЗАЛАР БЕЛӘН СЫНАЛЫРГА ТЕЛӘҮНЕҢ ХАТАЛЫ КАРАШ БУЛУЫ ТУРЫНДА.

Алдан әйтелгәнгә карамастан, сабырлык күрсәтеп бу зур әҗер-савапларны алам дип, кеше үзе өчен сынаулар һәм чирләр теләргә, һәм Аллаһтан аларны сорарга тиеш түгел. Бит шул ук савапларны Аллаһка шөкер итеп тә алырга мөмкин. Сахих хәдистә килә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Кем ризык ашый һәм Аллаһка рәхмәтләр әйтә, шул сабыр булып ураза тотучы кебек әҗер ала"*** – дигән. (Әхмәд, Ибн Мәҗәһ. Сахих хәдис. "Сахих әл-Җәмиг" 3943 китабын кара).

Шуннан инде күрәбез: кеше үзенең динен өйрәнмәгәч, күңеле турында кайгыртмагач һәм калеб гамәлләренә тиешле игътибар бирмәгәч, бик күп нәрсәләрдән мәхрүм кала. Чынлап та, ул бик зур әҗер-саваплар югалта! Мондый кеше гыйбадәтнең асылын күрми, шуңа күрә ул диннең бары тышкы формаларына гына игътибар бирә.

Шулай ук, ул, ахирәттәге газаптан котылам дип, Аллаһтан бу дөньяда үзен газапка тартуны сорарга тиеш түгел. Чөнки ул белми, үзенең тәвәккәллегенә карамастан, әгәр дә сораган авырлыклар килсә, түземлек күрсәтә алырмы, әллә сабырлыгы җитмәсме, көферлеккә төшеп китмәсме?! Тагын, мондый кеше Аллаһның киң рәхмәт һәм мәгъфирәт Иясе булуын аңлап бетерми, чөнки Аллаһ – Гафу итүче һәм гафу кылырга ярата. Гайшә رضي الله عنها сөйләгән хәдистә әйтелә, ул пәйгамбәребездән ﷺ сораган: *"Йә Аллаһ илчесе, әйт әле миңа, әгәр дә Кадер киче җиткәнен күрсәм, миңа нинди сүзләр әйтергә?"* Ул әйтте: ***"Әйт: йә Аллаһ, чынлыкта, Син – Гафу кылучы һәм Юмарт, гафу кылырга яратасың, мине гафу ит!"*** (Әт-Тирмизи, Ибн Мәҗәһ, әл-Хәким. Әт-Тирмизи, әл-Хәким һәм әл-Әлбәни хәдисне сахих диделәр. "Сахих әл-Җәмиг" 4423 китабын кара).

Аллаһ илчесе ﷺ үзенең өммәтен үз-үзләренә карата кырыслык күрсәтүдән кисәткән, хәдистә килгәнчә: ***"Үзегезгә карата кырыс булмагыз! Сезгә хәтле яшәгән кавемнәрне үзләренә карата кырыслык күрсәтүләре һәлак итте. Алардан соң калганнарны сез монах бүлмәләрендә һәм монастырьларда таба аласыз".*** (Әл-Бохари "әт-Тарих" 2/97 китабында. Хәсән хәдис. "Әс-Силсилә әс-Сахихә" 3124 китабын кара).

Шулай ук, башка сахих хәдистә хәбәр ителә, бервакыт пәйгамбәребез ﷺ бер кешенең хәлен белергә кергән, ә бу кеше шуның хәтле авыр хәлгә төшкән, хәтта чебеш кебек калган. Пәйгамбәребез ﷺ аннан: ***“Син догалар кылмыйсыңмы әллә, Раббыңнан сорамыйсың мени?”*** – дип сораган. Теге кеше: *“Әйе, сорыйм, мин: ““Йә Аллаһ, ахирәттә газапка тартканчы, бу дөньяда ук миңа газабыңны ашыктыр” дип әйтәм”* – дигән. Пәйгамбәребез ﷺ: ***“СөбханәЛлаһ! Син бит моны күтәрә алмаячаксың. Бәлки сиңа болай дип әйтергәдер: “Йә Аллаһ! Безгә дөньяда да һәм ахирәттә дә яхшылыкны бир һәм безне җәһәннәм утыннан сакла”?!”*** – дигән. *Шуннан ул аның өчен сорап Аллаһка дога кылган, һәм Аллаһ аны сырхауыннан терелткән”.* (Мөслим, 2688).

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Йә кешеләр, дошманнарыгыз белән очрашуны теләмәгез, Аллаһтан иминлек һәм саклау сорагыз, әмма инде алар белән очрашырга туры килсә – сабыр булыгыз һәм Җәннәтнең кылычларыгыз күләгәсендә булганын белегез!”*** – дигән. (Әл-Бохари 2965, Мөслим 1742).

Әбү Бәкер رضي الله عنه – бу өммәттә пәйгамбәребездән ﷺ соң икенче кеше – болай дип әйткән: “*Минем өчен – иминлектә булып Аллаһка шөкер итү, сыналып сабырлык күрсәтүгә караганда күпкә якынрак”* – дигән. (“Фәтхүл-Бәри”, 6/179).

Гәмр ибн әс-Сәканнан хәбәр ителә, бервакыт ул Суфьян ибн Гүйәйнә янында булганда Багдад шәһәреннән килгән бер кеше шундый сорау биргән: *“Йә Әбү Мөхәммәд, сиңа “Минем өчен – иминлектә булып Аллаһка шөкер итү, сыналып сабырлык күрсәтүгә караганда күпкә якынрак” дип әйткән Мүттарифның сүзләреме, әллә “Йә Аллаһ, Син миңа карата нәрсәгә риза – мин дә шуңа ризамын” дип әйткән Әбү әл-Әгләнең сүзләре өстенрәкме?”.* Шуннан Суфьян ибн Гүйәйнә уйга калган, аннан әйткән: “*Мүттарифның сүзләре миңа якынрак”* – дигән. Теге кеше: *“Ничек инде алай, бит икенчесе Аллаһ аңа нәрсә белән риза, ул да шуңа ризалык күрсәтә?!”* – дип сораган. Суфьян әйткән: *“Чынлыкта, мин Көръәнне укыдым һәм анда Сөләйман пәйгамбәрнең тарихын таптым, ул нык иминлектә яшәгән һәм, шул ук вакытта:* **“Нинди хуш бәндәдер ул Сөләйман, ул һәрвакыт тәүбә-тәсбих белән Аллаһка кайтучыдыр”.** (“Сад” сүрәсе, 30-нчы аять) – *дигән сүзләр белән сыйфатланган. Шулай ук, мин Әйюб пәйгамбәрнең тарихын күрдем, ул бик нык авырлыклар белән сыналган, әмма нәкъ шундый ук сүзләр белән сыйфатланган:* **“Ул Әйюб ни хуш бәндәдер, ул Аллаһка нык кайтучыдыр”.** (“Сад” сүрәсе, 44-нче аять). *Шулай итеп, бу ике сыйфат бер үк, ләкин аларның берсе иминлектә, ә икенчесе – сырхауда булган. Ягъни, шөкер итү – сабырлык күрсәтүгә тиңләнгән, димәк, болай булгач, миңа иминлектә яшәп Аллаһка шөкерле булу, сыналып сабырлык күрсәтүгә караганда күбкә якынрактыр”* – дигән. (“Хильятү әл-әүлия” 2/212 китабын кара).

Әмма инде сезгә яки туганнарыгызга берәр сырхау, бәла-каза һәм кайгы килсә, пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләрен исегездән чыгармагыз: ***“Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзенең колына югары дәрәҗә тели икән, әмма бу кешенең гамәлләре моңа ирешерлек булмаса, шул чакта Аллаһ аңа тәнендә, баласында яки малында төрле сынаулар бирә. Шуннан соң тиешле сабырлыгын җибәреп, Аллаһ Сөбхәнәһү вә Тәгалә аны Үзе тәкъдир кылган шул югары дәрәҗәгә күтәрә”.*** (Әхмәд 5/272, Әбү Дәүд 3090. Сахих хәдис. “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 1599, 2599 китабын кара).

Шулай ук, аның башка сүзләре: ***“Мөэминнең хәле бик гаҗәптер! Аның һәрбер халәте яхшылык, һәм мөэминнән кала бу башка беркемгә дә бирелмәгән. Әгәр дә аңа берәр сөенеч килсә, ул Аллаһка шөкер итә, һәм бу аның өчен яхшылыкка әверелә. Әгәр дә инде аңа берәр көенеч килсә – сабырлык күрсәтә, һәм монсы да аңа яхшылык белән тәмамлана”.*** (Мөслим, 2999).

Һәм инде Аллаһ Тәгаләнең Сүзләре: **“Бәлки сезгә яман булып күренгән әйбер – сезнең өчен хәерледер”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 216-нчы аять).

## АВЫРЛЫКЛАР ҺӘМ КУРКУ ВАКЫТЫНДА НАМАЗ УКУ ТУРЫНДА.

Чынлыкта, биш вакыт намаз – кеше белән Раббысы арасында бәйләнешне тотып тору өчен билгеләнгән. Бу иң мөһим тән гыйбадәте – дөньялыкның көенечләреннән, авырлыкларыннан һәм кыенлыкларыннан котылырга, ахирәттә газаптан имин калырга һәм бөек әҗерләргә ия булырга китерүче зур сәбәп.

Аллаһ Тәгалә мөэминнәргә мөрәҗәгать итеп әйтә: **“Йә мөэминнәр! Аллаһтан ярдәм сорагыз – тормыш вә дин юлындагы төрле авырлыкларга сабыр итеп һәм намазларыгызны үтәү белән”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 153-нче аять).

Имам әт-Табари бу аятьнең тәфсирендә: *“Аллаһ Тәгалә бәла-каза вакытында сабырлыкка һәм намаз үтәүгә юнәлергә кушты”* – дип әйткән. (“Тәфсир әт-Табари”, 1/610).

Имам әл-Бәгъауи аның тәфсирендә болай диде: *“Аллаһ Тәгаләдән, сабырлык күрсәтеп һәм намазларыгызны үтәп, төрле бәлалардан саклавын яки ахирәтне сорагыз”*. (“Тәфсир әл-Бәгъауи”, 1/89).

Хәфиз Ибн Кәсир әйткән: *“Аллаһ яхшырак белүче, әмма бу аятьнең мәгънәсе шундадыр – Муса пәйгамбәр һәм аның халкына фиргавен һәм аның тарафдарлары ягыннан сынаулар көчәйгәч, боларны күтәрергә авыр була башлагач, аларга ешрак намаз укырга боерылды”*. (“Тәфсир Ибн Кәсир”, 4/298).

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Пәйгамбәрләр курку вакытында намаз укыйлар иде”.*** (Әхмәд 4/332, әл-Бәззар 2089, әл-Бәйһәкъи 9/53, Ибн Наср “әс-Саляһ” 2/35 китабында. Хәдиснең дөреслеген Ибн Хиббән, әд-Дыя әл-Мәкъдиси, әл-Әлбәни, Мүкъбил ибн Һәди һәм Шүгәйб әл-Әрнәут

расладылар. “Әл-Мүхтәра” 51, “Әс-Силсилә әс-Сахихә” 1061, “Әл-Җәмиг әс-Сахих” 6/52, “Тәхриҗ әл-Мүснәд” 18937 китапларын кара).

Имам Әбү-л-Хәсән әс-Синди моның турында болай дип әйтте: *“Авырлыклар вакытында пәйгамбәрләрнең гадәте булып намаз уку иде”*. (“Хәшия гәлә Мүснәд әл-имәм Әхмәд”, 11/234).

Шулай ук хәбәр ителә, Хүзәйфә رضي الله عنه әйткән: ***“Аллаһ илчесен ﷺ берәр нәрсә борчыганда, ул намаз укый иде”*** – дигән. (Әхмәд 5/388, Әбү Дәүд 1319. Хәфиз Ибн Хәҗәр һәм шәех әл-Әлбәни хәдисне хәсән диделәр. “Фәтхүл-Бәри” 3/172, “Сахих Сүнән Әби Дәүд” 1192 китапларын кара).

Бу хәдиснең башка риваятендә Хүзәйфә رضي الله عنه әйткән: *“Хандәкъ сугышы алдыннан төнлә белән пәйгамбәребез ﷺ янына (разведкадан) кайткач, мин аның плащка төренгән хәлдә намаз укыганын күрдем. Аны берәр нәрсә борчыганда, ул намаз укый иде”*. (Ибн Наср әл-Мәрүәзи “Тәгзымү къадри-с-саляһ” 1/231 китабында. Шәех Әхмәд Шәкир хәдиснең дөреслеген раслады. “Гүмдә әт-тәфсир” 1/143 китабын кара).

Хәфиз Бәдрүддин әл-Гәйни бу хәдиснең аңлатмасында әйтте: *“Бу хәдистән шуны күрәбез – әгәр кеше авыр хәлгә кала икән, аңа намазга юнәлергә кирәк”*. (“Шәрх Сүнән Әби Дәүд” 5/226).

Имам әс-Сангәни шулай ук бу хәдискә аңлатма биргәндә әйтте: *“Пәйгамбәребез ﷺ көенеч һәм авырлыклар вакытында намаз укыган, чөнки монда намазның ярдәме бар һәм ул кешедән төрле бәлаларны һәм сагышларны этәрә. Бит намаз – башкаларны калдырып, бер Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, бары Аллаһ кына кешене төрле авырлыклардан һәм көенечләрдән коткара ала”*. (“Әт-Тәнүир” 8/368).

Гәбдүллаһ ибн Сәләм رضي الله عنه сөйләгән: *“Пәйгамбәребезнең ﷺ гаиләсендә берәр нинди бәла яки мәшәкать килеп чыкса, ул аларга намазга юнәлергә боера иде, һәм ошбу аятьне укый иде:* **“Гаилә әһелләреңә намаз укырга боер һәм үзең дә сабырлык белән аны үтә”.** (“Таһә” сүрәсе, 132-нче аять)*”*. (Әт-Тәбәрани “әл-Әүсат” 890 китабында, әл-Бәйһәкъи «Шүгәб әл-имән” 2911 китабында. Хәфиз әл-Һәйсәми хәдиснең тапшыручыларын ышанычлы, ә хәфиз әс-Суюты хәдиснең тапшыручылар чылбырын сахих диделәр. “Мәҗмүгү әз-зәүәид” 7/67, “әд-Дүрр әл-мәнсүр” 5/613 китапларын кара).

Шулай ук, пәйгамбәребезнең ﷺ сахәбәләренең дә гадәте шундый иде. Шулай хәбәр ителә, бервакыт Ибн Гәббәс رضي الله عنهما юлда булганда, аңа энекәше Къусәм вафат булуы турында җиткерәләр. Шуннан ул кайтуга таба борыла, кайту юлында читкә китеп, атланган җәнлегеннән төшә һәм, намазда утыруны озайтып, ике рәкәгать намаз укый. Намаздан торып баскач, үзенең җәнлегенә таба юнәлә һәм: **“Авырлыкны күтәрергә сабыр булып вә намаз укып Аллаһтан ярдәм сорагыз!”** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 45-нче аять) – дигән аятьне укый*”*. (Сәгыйд ибн Мәнсур “әс-Сүнән” 331 китабында, әт-Табари “әт-Тәфсир” 1/620 китабында, әл-Хәким 3067. Хәфиз Ибн Хәҗәр хәдиснең тапшыручылар чылбырын хәсән диде. “Фәтхүл-Бәри” 3/172 китабын кара).

Шулай ук, имам Ибн Наср әйткән: *“Әдәм عليه السلام һәм башка пәйгамбәрләр үрнәгеннән, мөэминнәр дөнья яки ахирәт белән бәйле берәр мөһим эшләрендә намаз аша Раббыларына мөрәҗәгать итүдән туктамадылар”.* (“Тәгзымү къадри-с-саляһ” 1/235 китабында).

Имам ибн Тәймийә әйткән: *“Хәвеф намазы һәртөрле куркыныч вакыйга вакытында укыла, булсынмы [Ай яки Кояш] тотылу, җир тетрәү, көчле җил һәм башкалар”.* (“Минһәҗ әс-сүннә” 5/445, “әл-Фәтәүә әл-күбра” 5/358).

Ибн Мүфлих кайгы төшкән кешегә *“Ике рәкәгать намаз укырга кирәк”* дигән имам әл-Әҗүрри һәм башка галимнәрнең сүзләрен китергән. Аннан ***“Аллаһ илчесен ﷺ берәр нәрсә борчыганда, ул намаз укый иде”*** дигән хәдис һәм, **“Авырлыкны күтәрергә сабыр булып вә намаз укып Аллаһтан ярдәм сорагыз!”** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 45-нче аять) дигән аятькә таянып, мондый вакытларда намаз укыган ибн Гәббәснең رضي الله عنهما гамәлен күрсәткән. (“Әл-Фүруг” 3/396 китабын кара).

Имам Ибн әль-Къаййим әйткән: “*Намаз – ризык артуга сәбәп булып тора, кешенең сәламәтлеген саклый, кайгылардан арындыра, чирләрдән дәвалый, калебне ныгыта һәм җанга сөенеч бирә. Шулай ук, ялкаулыкны этәрә, тәнгә активлык бирә, күңелне иркенәйтә, җанга азык булып тора, калебне һәм йөзне нурландыра, килгән нигъмәтләрне саклап тора, һәрнәрсәдә бәрәкәткә ирешүгә китерә, шайтаннан ерагайта һәм Рәхимле Аллаһка якынайта. Бер сүз белән әйткәндә, намаз – тән һәм җан сәламәтлегенең сакланып калуына һәм ныгуына бик нык тәэсир итә, зарардан котылуга китерә. Әгәр дә төрле бозым, чир, сынаулар һәм бәла-казалар белән сыналган ике кешене карасак – намаз укучының өлеше монда әзрәк, ә ахыр нәтиҗәсе күпкә иминрәк булачак. Шулай ук, намазның дөньялыкта булган зыянны этәрүдә гаҗәеп тәэсире бар, аеруча, намаз укучы үзенең намазына тиешле игътибарын бирсә, тыштан да, эчтән дә яхшы рәвештә үтәсә. Моның сере шундадыр – бит намаз кеше белән Аллаһ Тәгалә арасында бәйлелек булып тора, һәм Аллаһ колының Раббысы белән бәйлелеге ныграк булган саен, кешегә төрле хәерлек ишекләре ачылачак*”. (“Зәдү-л-Мәгәд”, 4/489-490).

Бу әйтелгәннәр ни өчен намаз пәйгамбәребезнең ﷺ тормышында шундый бөек урын алганын, ни өчен аның күңел рәхәтләге һәм ялы булганын аңлата. Мүгъира ибн Шүгбә رضي الله عنه сүзләреннән килә, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***“Намаз минем өчен күңел рәхәте итеп куелды”*** – дигән. (Әт-Тәбәрани “Әл-Кәбир” 20/420 китабында, әл-Хатыб “Тарих Бәгъдәд” 14/189 китабында. Сахих хәдис. “Сахих әл-Җәмиг” 3098 китабын кара).

Шулай ук, әлеге дәлилләр ачык рәвештә – курку, бәла-каза, авырлыклар, борчылу, авыртулар, көенечләр һ.б. вакытында намаз укуның тиешле гамәл булуын күрсәтәләр. Кызганычка каршы, күп мөселманнар өчен намаз күңелнең ялы түгел, киресенчә, хәтта аларга биш вакыт намаз да кыен булып күренә, нәфел намазларын әйтеп тә торасы түгел, әлбәттә инде, Аллаһ Тәгалә тарафыннан рәхим-шәфкать

кылынганнардан кала. Аллаһ Тәгалә әйткән: **“Авырлыкны күтәрергә сабыр булып вә намаз укып Аллаһтан ярдәм сорагыз! Намазларны вакытында үтәп бару авыр йөктер, мәгәр авыр булмас, Аллаһтан курыккан һәм рәхмәтен өмет иткән тәкъва кешеләргә”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 45-нче аять).

## АЛЛАҺНЫҢ РӘХМӘТЕ БЕЛӘН БӘЛАЛАР, ЧИРЛӘР ҺӘМ КӨЕНЕЧЛӘРДӘН АРЫНДЫРУЧЫ КАЙБЕР ДОГАЛАР.

• Сәгд رضي الله عنه исемле сахәбәдән хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Сезгә дөньялыкта кайгыга яки бәлага юлыккан кешене шул хәленнән коткаручы дога турында җиткеримме? Ул –*** **“Йә Аллаһ, синнән башка хак иләһ юк, Син һәр кимчелектән пакь, мин золымлык кылучылардан булдым”** (“Әл-Әнбия” сүрәсе, 87-нче аять) ***– дигән Зү-н-Нүннең*** *(Юныс пәйгамбәр)* ***сүзләре”.*** (Әл-Хәким, Ибн Әби әд-Дүньйә. Сахих хәдис. Әс-Суюты “әл-Җәмиг әс-Сагъир” 2846 китабында, “Сахих әл-Җәмиг” 2605 китабын кара).

**لاَ إِلَهَ إِلاَ أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ**

*/Лә иләһә иллә Әнтә, субхәнәкә, инни күнтү минә-ззалимин/.*

Бөек галим Ибн әл-Къаййим әйткән: *“Дөньялыктагы бәла-казаларны тәүхид[10] кебек бернәрсә дә этәрә алмый. Юныс пәйгамбәр дә тәүхид аша Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итеп авыр хәленнән котылды. Ә инде кешене зур хәсрәткә Аллаһ Тәгаләгә ширек[11] кылу китерә, һәм моннан бары тәүхидкә юнәлеп кенә имин калырга була. Тәүхид – һәрбер кешенең сыену һәм кайту җире, кальгасы, котылу урыны. Ә ярдәм һәм тәүфыйк Аллаһтан гына!”* (“Әл-Фәүәид”, 53).

• Хәбәр ителә, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә берәр кем сагышка, бәла-казага, сырхауга яки берәр авырлыкка юлыкса һәм “Аллаһ – минем Раббым, Аның тиңдәше юк” – дип әйтсә, бу*** *(дога)* ***аны боларның барысыннан да коткарыр”*** – дигән. (Әт-Тәбәрани. Хәсән хәдис. “Сахих әл-Җәмиг” 6040 китабын кара).

**اللهُ رَبِّ، لاَشَرِيكَ لَهُ**

*/Әллаһу Рабби, лә шәриикә ләһ/.*

• Ибн Мәсгүдтән رضي الله عنه хәбәр ителә, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә берәр кем борчылган яки күңелсезләнгән вакытында: “Йә Аллаһ, чынлыкта, мин – Синең колың, Синең колың булган ирнең улы, Синең колың булган хатын-кызның улы. Минем һәр эшем Синең кулында, миңа дигән хөкемнәрең – котылгысыз, тәкъдирең – гадел. Синнән һәрбер исемең аша сорыйм – Үз-үзеңне атаган исемең, яки***

---

10 Тәүхид – бериләһлек, барча гыйбадәтләрне бер Аллаһ Тәгаләгә юнәлтү. [Тәрҗемәчедән].
11 Ширек – күпиләһлек, Аллаһ Тәгаләгә кемне яки нәрсәне булса да тиңләү, Аннан кала башкаларга гыйбадәтләрне юнәлтү. [Тәрҗемәчедән].

***Китабыңда иңдерелгән исемең, яки Үзеңнең колларыңнан берәрсенә хәбәр иткән исемең, яки Үзеңнең гыйлемеңдә яшереп калдырган исемең – Көръәнне калебемнең язы, күңелемнең нуры кыл, кайгымның таралуына һәм борчуымның юкка-чыгуына сәбәпче ит” – дигән сүзләрне әйтсә, Бөек Аллаһ Тәгалә аны һичшиксез көенеченнән коткарыр һәм кайгысын сөенеч белән алыштырыр”***. Кешеләр сораганнар: *“Йә Аллаһ илчесе, безгә бу сүзләрне өйрәнергә кирәкме?”* Пәйгамбәребез ﷺ: ***“Әлбәттә, кем бу сүзләрне ишетте, аңа аларны өйрәнергә тиешле”*** – дип җавап биргән”. (Әхмәд 1/391, Ибн Хиббән 3/972, әт-Тәбәрани 10352. Хәдиснең дөреслеген әл-Хәким, әл-Бәгъауи, шәйхүл-Исләм ибн Тәймийә, Ибн әл-Къаййим, Ибн Хәҗәр һәм әл-Әлбәни расладылар).

**أَللَّهُمَّ إِنِّي عَبْدُكَ، ابْنُ عَبْدِكَ، ابْنُ أَمَتِكَ، نَاصِيَتِي بِيَدِكَ مَاضٍ فِي حُكْمُكَ، عَدْلٌ فِي قَضَاؤُكَ، أَسْأَلُكَ بِكُلِّ اسْمٍ هُوَلَكَ، سَمَّيْتَ بِهِ نَفْسَكَ أَوْأَنْزَلْتَهُ فِي كِتَابِكَ، أَوْ عَلَّمْتَهُ أَحَدًا مِنْ خَلْقِكَ، أَوِاسْتَأْ ثَرْتَ بِهِ فِي عِلْمِ الْغَيْبِ عِنْدَكَ أَنْ تَجْعَلَ الْقُرْآنَ رَبِيعَ قَلْبِي، وَنُورَ صَدْرِي، وَجَلاَءَ حُزْنِي وَذَهَابَ هَمِّي**

*/Әллаһүммә инни гәбдүк, ибнү гәбдик, ибнү әмәтик, нәәсыяти бийәдик, мәәдын фийә хүкмүк, гәдлүн фийә къадааүк, әс-әлүкә бикүлли-смин һүә ләк, сәммәйтә биһи нәфсәк, әү әнзәлтәһү фи китәәбик, әү гәлләмтәһү әхәдән мин хъалькъик, әү-истәәсәртә биһи фи гилмил-гъайби гиндәк, ән тәҗгәләл-Къурәнә рабиигә къалби, үә нүүра садри, үә җәләә-ә хүзни, үә зәһәәбә һәмми/.*

- Гүмәр ибн әл-Хаттабтан رضي الله عنه хәбәр ителә, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә берәр кем берәр нәрсә белән сыналган кешене күрсә һәм: “Аллаһка барча мактау булсын, Ул сине сынаганнан мине имин кылды һәм Үзе бар иткән күп затлардан мине хөрмәтләде” – дип әйтсә, бу кеше әлеге сынаудан имин булыр”.*** (Әт-Тирмизи 3432, Ибн Мәҗәһ 3892. Хәсән хәдис).

Шәех әл-Мүбәракфүри әйткән: *“Ягъни, кеше тәнендә берәр нәрсә белән сыналган булса, мәсәлән, проказа, кыска яки артык озын буйлылык, сукырлык, аксаклык, куллары кәкре булу һ.б. Яки динендә сыналган булса, мәсәлән, бозыклык, золымлык, дингә яңалык кертү, көферлек һ.б.”* (“Түхфәтүл-әхүәзи”, 10/234).

Хәфиз ән-Нәүәүи әйткән: *“Бу доганы теге кеше ишетмәслек итеп әйтергә кирәк, чөнки бу сүзләр аның йөрәгенә тиергә мөмкин. Әгәр дә инде, аның сынауы булып гөнаһ кылу торса, бу очракта кычкырып әйтүдә бернинди проблема юк”*. (“әл-Әзкәр”, 368).

**اَلْحَمْدُ لِلهِ الَّذِي عَافَانِي مِمَّاابْتَلَكَ بِهِ، وَفَضَّلَنِي عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً**

*/Әльхәмдү ли-Лләһи лләзи гәәфәәни миммә-бтәләкә биһи, үә фәддаләни гәлә кәсирин миммән халәкъа тәфдыйлә/.*

• Гүсмән ибн Гәффәннән رضي الله عنه риваять кылына, Аллаһ илчесе ﷺ әйткән: ***“Кем иртә һәм кич өч тапкыр: “Аллаһ исеме белән. Аның исеме белән җирдә һәм күктә һичнәрсә дә зыян китерә алмый, бит Ул – Ишетүче, Белүче” – дип әйтә, Аллаһның бу колына берниндә дә зарар ирешмәс”.*** (Әт-Тирмизи 3388, әл-Бохари “Әл-әдәб әл-мүфрад” 660 китабында. “Сахих әл-Җәмиг” 6426 китабын кара).

**بِسْمِ اللَّهِ الَّذِي لاَ يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَيْءٌ فِي الأَرْضِ وَلاَ فِي السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ**

*/Бисми-Лләһи лләзи лә ядурру мәгә-смиһи шәй-үн фил-әрды үә лә фи-ссмәә-и, үә һүә-Ссәмиигүл-Гәлим/.*

Бу хәдисне тапшыручы Әбән (Гүсмән ибн Гәффәннең улы) әйткән: *“Мин Гүсмән ибн Гәффәннең сүзләрен ишеттем, ул Аллаһ илчесенең ﷺ сүзләрен ишеткән...”* – аннан әлеге хәдисне китергән.

Әмма Әбән ибн Гүсмән үзе паралич белән интеккән, шуңа күрә бу хәдисне сөйләгән җыенда аңа бер кеше шикләнеп карап куйган. Шуннан Әбән бу кешегә: *“Нигә миңа болай карыйсың? Аллаһ белән ант итәм, мин Гүсмәннән ялган сөйләмим, һәм Гүсмән дә пәйгамбәребездән ﷺ ялган сөйләмәде. Әмма ул көнне мин бик ачулы идем һәм бу сүзләрне әйтмәдем, һәм менә шушы хәлгә очрадым”.* (“Сахих Сүнән Әби Дәүд” 5088 китабын кара).

• Ибн Гүмәрдән رضي الله عنه хәбәр ителә, ул әйткән: *“Аллаһ илчесе ﷺ, беркайчан да калдырмыйча, иртән һәм кичен әлеге сүзләрне әйтә иде:* ***“Йә Аллаһ, Синнән сорыймын мине бу дөньяда да һәм ахирәттә дә гафу итүеңне һәм иминлек бирүеңне. Йә Аллаһ, сорыймын Синең гафу кылуыңны һәм динемдә, дөньямда, гаилә әһелләремдә һәм малымда һәрбер начарлыктан саклавыңны. Йә Аллаһ, минем гаурәтемне капла һәм куркудан имин кыл. Йә Аллаһ, мине алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да, өстән дә сакла, һәм Синең Бөеклегең аша яклау сорыймын, минем хыянәтләрчә астан һәлак ителүемнән”.*** (Әхмәд 2/25, Әбү Дәүд 5074, Ибн Мәҗәһ 3871. Сахих хәдис. “Сахих әт-Тәргъиб” 655 китабын кара).

**اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَ الْعَافِيَةَ فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ، اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَ الْعَافِيَةَ فِي دِينِي وَدُنْيَايَ وَأَهْلِي وَمَالِي، اللَّهُمَّ اسْتُرْ عَوْرَاتِي وَآمِنْ رَوْعَاتِي، اللَّهُمَّ احْفَظْنِي مِنْ بَيْنِ يَدَيَّ، وَمِنْ خَلْفِي، وَعَنْ يَمِينِي، وَعَنْ شِمَالِي، وَمِنْ فَوْقِي، وَأَعُوذُ بِعَظَمَتِكَ أَنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحْتِي**

*/Әллаһүммә инни әс-әлүкә әл-гәфүә үәл-гәәфиятә фи-ддүнйә үәл-әәхыра. Әллаһүммә инни әс-әлүкә әл-гәфүә үәл-гәәфиятә фи диини үә дүнйәйә үә әһли үә мәәли. Әллаһүммә-стүр гәураати үә әәмин раугәәти. Әллаһүммә-хфазни мин бәйни йәдәййә үә мин хальфи үә гән йәмиини үә гән шимәәли үә мин фәукъи. Үә әгүүзү би гәзамәтикә ән үгътәәлә мин тәхти/.*

• Шулай хәбәр ителә, бервакыт Гүсмән ибн Әбүл-Гәс رضي الله عنه Аллаһ илчесенә ﷺ тәнендә авырту сизгәненә зарланган һәм пәйгамбәребез ﷺ аңа әйткән: ***“Авырткан***

***урыныңа кулыңны куй һәм өч мәртәбә “Аллаһ исеме белән!”, аннан җиде мәртәбә “Шушы тойгымның зыяныннан һәм куркуымнан Аллаһка һәм Аның Кодрәтенә сыенамын” – дип әйт”*** – дигән. (Мөслим, 2202).

**أعُوذُ بِعِزَّةِ اللهِ وَقُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ وَ أُحَاذِرُ**

Өч тапкыр: */Бисми-Лләһ/.*

Җиде мәртәбә: */Әгүүзү би-гиззәти-Лләһи үә къудратиһи мин шәрри мә әҗидү үә үхәәзир/.*

- Әбү Һурайрадан رضي الله عنه хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Авыр сынаулардан, афәтләрдән һәм бәхетсезлекләрдән, начар тәкъдирдән һәм дошманнарның явызлыгыннан Аллаһтан саклау сорагыз”*** – дигән. (Әл-Бохари 6616, Мөслим 2707).

**اللهمَّ إنِّي أعُوذُ بِكَ مِنْ جَهْدِ الْبَلَاءِ، وَدَرَكِ الشَّقَاءِ، وَسُوءِ الْقَضَاءِ، وَشَمَاتَةِ الْأَعْدَاءِ**

*/Әллаһүммә инни әгүүзү бикә мин җәһдил-бәләә-и, үә дәраки-ш-шәкъаа-и, үә сүү-ил-къадаа-и, үә шәмәәтәтил-әгдәә-и/.*

- Әбү Гүсмән әл-Һинди сөйләгән, бервакыт Гүмәр ибн әл-Хаттаб رضي الله عنه елый-елый Кәгбәтуллаһ тирәли тәваф кылганда шундый сүзләр әйткән: *“Йә Аллаһ, әгәр дә Син мине бәхеткә ирешүчеләр исемлегендә язгансың икән – мине алар арасында булуны ныгыт, ә әгәр дә Син миңа бәхетсезлек һәм гөнаһлар язгансың икән – моны сөрт тә, мине бәхетлеләр рәтендә ныгыт!”* (Әт-Табари “әт-Тәфсир” 13/167 китабында, әл-Бәйһакъи «әл-Къада үәл-къадар” 189 китабында, әл-Фәкиһи “Ахбәр Мәккә” 1/229 китабында. Хәдиснең дөреслеген әл-Һәйсәми, Ибн Кәсир һәм әл-Әлбәни расладылар. “Мәҗмүг аз-зәүәид” 10/185, “Мүснәд Фәрукъ” 841, “әс-Силсилә әд-Дагыйфә” 11/763 китапларын кара).

**أَللَّهُمَّ إنْ كُنْتَ كَتَبْتَنِي فِي أَهْلِ السَّعَادَةَ فَأَثْبِتْنِي فِيهَا، وَإِنْ كُنْتَ كَتَبْتَ عَلَيَّ الذَّنْب وَالشِّقْوَةَ فَامْحُنِي وَأَثْبِتْنِي فِي أَهْلِ السَّعَادَةَ**

*/Әллаһүммә ин күнтә кәтәбтәни фи әһли-ссәгәәдәти фә-әсбитни фиһә, үә ин күнтә кәтәб-*
*тә гәләййә-ззәнбә үә-шшикъүәтә фәмхүни үә әсбитни фи әһли-ссәгәәдәһ/.*

- Шәригатьтә күрсәтмә булган саваплы гамәлләрне күбрәк кылу.

Әнәс رضي الله عنه исемле сахәбәдән риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйткән:
***“Саваплы гамәлләр кылу начар үлемне, чирләрне һәм хәвеф-хәтәрләрне этәрә”.***
(Әль-Хәким 429. Сахих хәдис. “Сахих әл-Җәмиг” 3795 китабын кара).

Имам ибн аль-Къаййим әйтте: *“Саваплы гамәлләр, кешеләргә яхшылык кылу, Аллаһка еш зекер әйтү һәм догада булу шифалану-савыгуга иң яхшы сәбәпләр булып торалар. Шулай ук, Аллаһ каршында басынкы булу, түбәнчелек белән Аңа дога кылу һәм*

*тәүбәгә килү дә шул сәбәпләрдән. Болар барысы да кешене савыгуга китерә һәм чирләрдән ерагайта. Бу сәбәпләр хәтта даруларга караганда да көчлерәк тәэсир бирәләр. Ләкин аларның тәэсире кешенең эчке халәтенә, аның шушы сәбәпләрне инанган хәлдә кабул итүенә һәм аларның файдасына ныклы ышануыннан тора”.* (“Зәдү-л-Мәгәд” китабы).

• Шулай ук, кеше, булсынмы гарәп телендә, булсынмы үз телендә, башка догалар белән дә Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итә ала.

Ибн Гүмәрдән رضي الله عنهما хәбәр ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Дога кылу – бәла килгәч тә, килгәнче дә файда китерә. Шуңа күрә күбрәк дога кылыгыз, йә Аллаһ коллары!”.*** (Әт-Тирмизи 3548. Сахих хәдис. “Сахих әл-Җәмиг” 3409 китабын кара).

*Һәм, ахырдан, галәмнәр Раббысы Аллаһка барча мактауларыбызны җиткерәбез! Мөхәммәд пәйгамбәргә, аның гаилә әһелләренә, сахәбәләренә һәм ихласлы рәвештә аларның юлына иярүчеләргә Аллаһның мактавы, сәламе һәм бәрәкәте булсын!*